ЗӨФӘР ДӘҮЛӘТШИН: «Якташларыбыз янына тагын барачакбыз»

> 3

БИТЛЕКЛӘР ӘЗЕР Коронавирус кабат әйләнеп кайтырга мөмкин

> 4

БЕЗНЕҢ ТУФАН! Якташлары әдипне искә алды

> 5

ХА-ХА-ХАНӘ Булмас димә, кызык-мызык, фототөрткеләр – монда

> 8

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 127–128 (29094–29095) | Сишәмбе | 5 сентябрь | 2023 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

БЕЛЕМГӘ ЮЛ

Мәгариф

Белем көнендә республикада 11 яңа мәктәп ачылды. Заманча уку йортлары укучыларны шәһәрдә дә, авылда да кабул итте. Быел 1 нче сыйныфка баручылар 57 меңгә җитте хәтта. Балалар саны арту – күңелле күренеш. «ВТ» хәбәрчесе яңа ачылган уку йортларындагы вазгыятьне белеште, шулай ук Казанда ачылган «Ачыш» гимназиясендәге шартлар белән дә танышып кайтты.

tatarstan.ru

Замана кушканча

1 сентябрь көнне Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов башта «Ачыш» гимназиясен ачу тантанасында катнашты. Әлеге белем йорты 1224 балага исәпләнгән. 1 нчегә 9 сыйныф туплаганнар. Арада хәтта «Ә» дигәне дә бар.

– Әлеге яңа мәктәп – заманча мәктәпләрнең үрнәге. Без мондый уку йортларын күптән төзибез. Әмма аларга елдан-ел ниндидер үзенчәлек өстәлә бара. Теләгем шул: балалар татулыкта, тынычлыкта үссен. Республика икътисады алга барсын, башкалабыз тагын да матурайсын. Ә иң мөһиме – барлык балалар да исән-сау, сәламәт булсын! – диде Рөстәм Миңнеханов.

Казан мэры Илсур Метшин әйтүенчә, быел республика Рәисе һәм федераль программалар ярдәмендә 6 мең балага исәпләнгән дүрт яңа мәктәп ачылган. Казанда беренче тапкыр 20 мең бала 1 нче сыйныфка барган. Бу – рекордлы сан. 2025 елга тагын 20 мең беренче сыйныф укучысын көтәләр.

«Ачыш» гимназиясендә озайтылган көн төркемнәре өчен уен бүлмәләре, ике спорт залы, душ бүлмәләре, бассейн да бар. Укучылар футбол, волейбол, теннис уйный, тренажерларда шөгыльләнә алачак.

Рөстәм Миңнеханов Россия вице-премьеры Дмитрий Чернышенко белән Иннополис университетының яңа тулай торак биналарын ачу тантанасында да катнашырга өлгерде. Тулай торaклар өчен федераль бюджеттан 2,5 миллиард сум акча бүлеп бирелгән.

– Федераль Хөкүмәтнең ярдәме, илебездә үткәрелә торган зур эшләр нәтиҗәсе бу. Университетны үстерү өчен шушы өч бина кирәк иде. Алар планнан тыш булдырылды, – диде Рәис.

Иннополиста уңайлы яшәү һәм эшләү өчен барлык мөмкинлекләр дә тудырылган. Бу – Россиядә иң алдынгы уку йортларының берсе.

Дмитрий Чернышенко билгеләп үткәнчә, илдә «Фән һәм университетлар» илкүләм проекты буенча студентларның тулай торакларын булдыруга 13,5 миллиард сум акча бирелгән.

Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин исә «Салават Күпере» торак комплексындагы 182 нче политехника лицееның яңа бинасын ачты. Белем йорты 1500 урынга исәпләнгән. Бирегә югары сыйныф укучылары белем алачак.

Фәрит Мөхәммәтшин республика мәктәпләрендә белем бирү системасын үстерү өчен бик күп эшләр башкарылуын әйтте. Ул укучыларга компьютерлар сатып алу өчен сертификат һәм волейбол кирәк-ярагы тапшырды. «Лицей командасының Мәктәп волейбол лигасында актив катнашачагына ышанам», – диде Дәүләт Советы Рәисе.

Ите – сезгә, сөяге – безгә

Яңа мәктәпләр әкияттәге кебек матур, әлбәттә. Кубесенең бассейны, актлар залы бар. Заманча җиһазлар белән җиһазландырылган. Монысы да бик мөһим. Тик укучы дивардан гына хәл итми. Яңа мәктәпләрнең әлегә укыту тәҗрибәсе дә юк. Барысын җайга салганчы ким дигәндә 5–6 ел вакыт үтү кирәк. Әти-әниләр моңа әзер.

Минзилә Шәйхетдинова оныгы Алияне мәктәпкә озата килгән. Алия 1 нче «Н» сыйныфына укырга бара. Булачак инженерлар сыйныфы бу. Кызчык 5 яшьтә укырга, язарга өйрәнгән.

– Балалар исән-сау булып, тырышып укысыннар иде. Ә укытучыларга сабырлык телим, – диде ул. – Бәйрәмдә үзем дә мәктәп елларын искә төшердем. Питрәч районының Чыты мәктәбен тәмамладым мин. Әниебез гел эштә булды. Шуңа күрә мәктәпкә әбиебез илтте. Шул вакытта укытучыга: «Менә, Мәрзия, ите – сезгә, сөяге – безгә», – дип, мине укытучыга тоттырды. Хәзер әти-әниләр башка шул. Алар укытучыны түгел, үз баласын якларга тырыша.

«Әкият» татар дәүләт курчак театрының баш режиссеры Илгиз Зәйни һәм шагыйрә Резеда Гобәева улы Хәйдәрне 1 нче сыйныфка озата килгән. Хәйдәр дә 5 яшьтән үзе укырга, язарга өйрәнгән. Берзаман бөтен язуларны укып йөри башлаган. Илгиз белән Резедә үзләре дә аңламыйча калган хәтта.

– Улыбызны татар сыйныфына махсус бирдек. «Ә» сыйныфында белем алачак. «Сәләт»нең «Асылташ» мәктәбенә бәйле ул. Мәктәпне сайлаганда, тел мәсьәләсенә, укытучыга игътибар иттек. Яхшы укытучы укыту бик мөһим. Аның балаларны тормышка әзерли белүе кирәк. Укытучылары җитсә, бер сыйныфта артык күп бала укымаса, мәктәптә ничә сыйныф булу мөһим түгел, минемчә, – ди Илгиз Зәйни.

Ахыры 4 нче биттә >

Әйбәт!

Татарстанда яшәүчеләрнең хезмәт хакы күләме быел гыйнвардан июнь аена кадәр узган елның беренче яртыеллыгындагы белән чагыштырганда 11,5 процентка арткан. Татарстанстат мәгълүматлары шул хакта сөйли.

Росстат белдергәнчә, гыйнвар – май айларында Татарстанда айлык уртача хезмәт хакы күләме Идел буе федераль округы төбәкләре арасында иң югары дәрәҗәдә булган. Шушы чорда республикада яшәүчеләрнең кереме 8,7 процентка арткан. Татарстанда хезмәткәрләр аена уртача 57,4 мең сум күләмендә акча алып эшләгән. Финанс министрлыгы мәгълүматларына караганда, бу күрсәткеч узган елдагыдан 16,4 процентка зуррак.

Рәхмәттән башка сүз юк

Россия укучылары информатика буенча халыкара олимпиадада 4 алтын медаль яулаган. Шуның икесе – Татарстаннан: Казанның 2 нче лицей-интернаты укучысы Гыйлман Абдуллин һәм КФУның Лобачевский исемендәге лицее укучысы Валерий Родионов.

«Котлыйбыз! Укытучыларга – аерым рәхмәт сүзләре! Без сезнең белән горурланабыз! Яңа уңышлар телибез!» – дип язган Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов үзенең телеграм-каналында.

Сүз уңаеннан, республика халыкара, Россия һәм республика күләмендәге олимпиадаларда җиңгән өчен мәктәп укучыларына түләү күләме арттырылган. Премьер-министр Алексей Песошин бу җәһәттән тиешле указга кул куйган. Шулай итеп, халыкара олимпиадада җиңгән өчен – 459ар мең сум, икенче урынга – 402 мең сум, өченче урынга 344әр мең сум акча каралган.

Россия күләмендәге олимпиаданың йомгаклау этабында җиңгән өчен – 200әр мең сум, призлы урыннар яулаган өчен 100әр мең сум күздә тотылган. Ә инде республика күләмендәге олимпиадада җиңүчеләргә 10ар мең сум бирәләчәк.

Педагогларга килгәндә, республика олимпиадаларына укучылар әзерләүчеләр балага түләнгән сумманың 100 проценты күләмендә акча алачак. Укучылары халыкара олимпиадаларда призлы урыннарны яулаган педагогларга исә укучыга бүленә торган акчаның 50 проценты күләмендә түләнәчәк.

Кайтып киткәннәр

Татарстанның суд приставлары идарәсе хезмәткәрләре быел 8 айда Россиядә яшәү шартларын бозган 946 чит ил кешесен өйләренә кайтарып җибәргән.

Мигрантлар башта Чаллы шәһәрендә урнашкан Чит ил кешеләрен вакытлыча тоту үзәгенә китерелә. Юл билетлары сатып алынгач, суд приставлары тәртип бозучыларны Россия дәүләт чиге аша үзу урынына – аэропортка кадәр озата. Анда исә алар чик буе хезмәткәрләренә тапшырыла.

Бу юлы Әфганстан, Куба, Таҗикстан, Үзбәкстан, Әрмәнстан, Төркия кебек илләрдән килүчеләр өйләренә кайтып китәргә мәҗбүр булган.

Яңалык

Сентябрь ае үзгәрешләре

1 сентябрьдән яңа законнар үз көченә керде. Көзнең беренче аенда тормышыбызда нәрсәләр үзгәрә?

✓**Пенсия арта.** Эшләмәүчеләрнең пенсиясе автомат рәвештә индексацияләнә. Моннан тыш сентябрьдә 80 яшен тутыручыларның пенсиясенә 7567 сум 33 тиен өстәлә. 80нән узган өлкәннәр бу өстәмәне алып килә инде.

✓**Таксист тормышы үзгәрә.** 1 сентябрьдән такси турында яңа закон үз көченә керә. Хәзер таксист гамәлдәге ОСАГО полисына ия булырга тиеш, юкса пассажир йөртү хокукыннан мәхрүм ителә. Моннан тыш аның эш сменасы озынлыгы чикләнә: үл бер сменага күп дигәндә – 12 сәгать, атнасына күп дигәндә 40 сәгать кенә эшләргә тиеш.

✓**Түләүле медицина хезмәте күрсәтүнең яңа кагыйдәләре гамәлгә керде.** Алар буенча, түләүле хезмәтләр турында килешү төзегәндә, сырхауга әлеге ярдәмне бушлай да алып булу мөмкинлеге турында әйтелергә тиеш. Шулай ук дәвалануны тәгаен күпме көтәргә туры киләчәген җиткерү таләп ителәчәк.

✓**Инвалид балаларның әти-әниләренә өстәмә ял бирелә.** 1 сентябрьдән башлап, мондый балаларның ата-аналары һәм опекуннары рәттән 24 көн өстәмә түләүле ял аларга мөмкин. Баланы шифаханәгә алып килеп, сәламәтләнгән нигыту өчен тудырылган мөмкинлек бу. Моңа кадәр әти-әниләр әлеге максатта чираттагы ялларыннан файдаланган.

✓**Ислам банкинггың сынау.** Илнең дүрт төбәгендә – Татарстанда, Башкортстан, Дагыстан һәм Чечнягә ислам банкингы буенча эксперимент кертелә. Бу ике ел дәвам итәчәк, әмма сынау вакыты үзгәртелергә дә мөмкин. Халыкка финанс хезмәтләре күрсәтүдә шәригать канунлары үтәләчәк. Болар – акчаны процентка бирәп торуны, кешене бөтен акчасы һәм мөлкәтеннән коры калдырырдай инвестицияләрне, хәмер, тәмәке, дуңгыз ите белән сәүдә итүгә, шулай ук комарлы уеннар, күңел ачулар өлкәсенә инвестицияләрне тыю.

✓**Электрон тәмәкегә минималь бәя.** 1 сентябрьдән вейпларның һәм алар өчен сыекчаның минималь бәяләре билгеләнәчәк.

✓**Мәктәпләргә белем бирүнең бердәм стандарты кертелә.** Россия мәктәпләре федераль программалар буенча гына эшли башлаячак. Ике ел эчендә фәннәргә укытуның бер үк төрле тәртибе булдырылырга тиеш.

✓**Баланы башка мәктәпкә күчерүнең яңа кагыйдәләре.** Хәзер баланы башка мәктәпкә күчерү өчен документларны шәхсән үзең барып яки Купфункцияле үзәк, Дәүләт хезмәтләре порталы аша тапшырырга мөмкин. Шул ук вакытта мәктәпне алыштыру сәбәбен күрсәтергә кирәк булачак. Әйтик, буш урыннар булмаганда яки бала сынау сорауларына җавап бирә алмаганда, мәктәпкә алудан баш тартырга мөмкиннәр.

✓**Вуз яки көллият студентлары өчен яңа ташламалар.** Махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның балалары бюджет урынына күчү өчен яңа ташламага ия булачак. Зачет һәм имтиханнар буенча «койрык»лары, укуга түләү буенча бурычлары, шелтәләре булмаса, алар түләүле укудан түләүсезгә күчәргә мөмкин. Шул ук вакытта махсус хәрби операциядә катнашучы яки анда катнашучы хәрби белән туганлык элементләрен документлар нигезендә расларга кирәк булачак. Бу кагыйдә киләсе елның 31 августына кадәр гамәлдә булачак.

Сүзгә-сүз

Рамил МУЛЛИН, Түбән Кама районы җитәкчесе, шәһәр мэры:

Әлегә Түбән Камада хәрәкәт итү тизлеге югары. Төп бурычыбыз – куркынычсызлык. Кеше бер ноктадан икенчесенә исән-имин барып җитәргә тиеш. Шуңа күрә Түбән Камада уртача хәрәкәт итү тизлеген сәгатенә 40 чакрымнан да арттырмаска кирәк.

(«Эшлекле дүшәмбе» киңәшмәсеннән)

ТАТАРСТАНДА – КЫР ЭШЛӘРЕ

Республикада урып-җыю эшләренең 97 проценты башкарылган, дип хәбәр итә Татарстан Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы. Бөртеклеләрне суктыру эшен 15 район тәмамлаган.

Урып-җыю эшләре	**1,4 млн га**
Уртача уңыш	**26,0 (ц/га)**
Суктырылган	**3669,7 мең т**

*Татарстан Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы мәгълүматлары

Яшенле яңгыр килә

Бу көннәрдә Татарстанда җылы булачак. Әмма пәнҗешәмбе – 7 августтан берничә градуска салкынайта.

Гидрометеоүзәк мәгълүматлары буенча, чәршәмбе – 6 сентябрьдә көндез +20…+25 градус җылы саклана әле. Төнге сәгатьләрдә +9…+14, республиканың көньяк һәм көнчыгыш төбәкләрендә +5…+8 градус. Әмма һава торышы бозыла: иртән һәм көндез кыска вакытлы яшенле яңгырлар явып үтәчәк. Секундына 16 метрга кадәр көчле җил котелә.

Пәнҗешәмбе – 7 сентябрьдә республикага салкынча һава агымы үтеп керәчәк. Яңгыр булачак. Көндез термометрның терекөмеш баганасы +14…+19 градустан югары күтәрелмәячәк. Төнлә +9…+14.

Синоптикларның баланнгыч мәгълүматлары буенча, җомга – 8 сентябрьдә урыны белән яңгырлар явып үтәчәк. Һава температурасы тагын берничә градуска төшеп, көндез +12…+17, төнлә +4…+9 градус чикләрендә тирбәләчәк.

Шимбә – 9 сентябрьдә көндез +16…+21 градус җылы. Яңгыр булырга мөмкин.



Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Дөньяда

КӨНБАТЫШНЫҢ КӨЧСЕЗЛӘНҮЕМЕ?

Франция Президенты Макрон: «Дөнья аренасында хәл катлаулана, Көнбатышның һәм Европаның көчсезләнү куркынычы бар», – дип белдерү ясады. Африкадагы вазгыять Франциягә уңай түгел. Дистәләгән илне савып яшәгән Париж соңгы атналарда бер-бер артлы позицияләрен югалта. 92 француз сенаторы Макронга ачык хат язды. Ул хатта: «Бүген Нигер, кичә Мали, Үзәк Африка Республикасы һәм Буркина-Фасо француз гаскәрләрен, француз компанияләрен кире какты», – дигән сүзләр бар һәм бу мәсьәләдә катгый позициягә басу таләбе ярылып ята. Франция соңгы сигез елда биш Африка илендә баш күтәргән җирле халыкларга каршы хәрби операция алып барды һәм нәтиҗәгә ирешмичә, зур чыгымнар йөге авырлыгы астында гаскәрләрен чыгарырга мәҗбүр булды. Үткән атнада Габон баш күтәрде. Анда Президент сайлавы булган иде. Ил белән 14 ел идарә иткән Ондимба сайлауда җинде, тик армия, сайлау нәтиҗәләре фальсификацияләнде, дип игълан итеп, баш күтәрде. Габон – нефть запаслары ягыннан Африкадагы алтынчы ил, башка күп төрле табигый байлыклар да аяк астында аунап ук диярлек ята. Халкы гадәттән тыш фәкыйрь. Аның каравы Президент өендә дистәләгән килограмм евро һәм доллар табылды.

Африкада дәүләт түнтәрелешләре – гадәти хәл. Әмма быелгы вазгыять элеккеләреннән аерыла. Элек хакимиятләр белән фетнәчеләр урын алышалар да, халыкны талаучыларның исеме генә үзгәрә иде. Быел Африкадан французлар себерке белән кугандай куыла. Габондагы Eramet француз тау компаниясе эшчәнлеген туктатты.

Көнбатышлыларның чигенүе Африкада гына түгел, Сүриядә дә күзәтелә. Соңгы көннәрдә илнең төньягындагы Дәйр-әз-Зор төбәгендә гарәп кабиләләре французлар һәм америкалылар яклавы астындагы YPG/PKK (көрд эшчеләр партиясе) террорчыларына каршы баш күтәрде. Мәчетләрдә коммунистик карашлы бу партиягә каршы җиһадка чыгарга өндәүләр яңгырады. Үз кулы астында булган һәр җирдә кан кою һәм вәхшәт таратучы YPG/PKK байтак позицияләрен югалтты. Исегезгә төшерәбез: бу партиягә каршы рәсми Әнкара даими рәвештә хәрби операцияләр үткәрә. Дөресен әйткәндә, Сүриядәге сәяси һәм кораллы көрәш палитрасы бик күп төсләр җыелмасыннан тора. Дәйр-әз-Зорда баш күтәргән халык, мәсәлән, Әсәдның отставкасын, Иран һәм Россия көчләренең Сүриядән китүен таләп итә. Лабиринтлар эчендә шайтан аягын сындырырлык, кыскасы. Әмма Сүрия – киләчәкнең зур тартыш мәйданына әвереләчәк урын һәм бер көч тә аны үз иреге белән ташлап китмәячәк.

Россиядә

СУМДА БАЙЛЫК САКЛАРГАМЫ?

Россиядәге вазгыять глобаль дөньядагы хәлгә нык охшаган. Ихтимал без тотрыклылык дигән сүз белән озакка саубуллашырбыз. Нәбиуллина: «Үзәк банк даими рәвештә икътисадый шокка әзер булырга тиеш», – дигән белдерү ясады. Үзәк банкның әзерлеге процент ставкасын күтәрү, кредитлауны киметүдән гыйбарәт. Беренчесе – процент ставкасы – якын киләчәктә төшмәячәк, ә күтәрелергә бик мөмкин. Бу – Үзәк банкның рәсми позициясе. Үзәк банк кулланучылар кредитын бирүгә чикләүләрне көчәйтте. Кредитлар хисабына гына үсүче икътисад өчен сөенечле хәбәрләр түгел болар. Гайкаларны кысу шартларында да финанс хәле ышанычлы түгел: инфляция давылы кузгалам дип кенә тора, процент ставкасы күтәрелгәч, ныгыган сум яңадан түбәнәя. Ставропольеда бер литр дизель ягулыгының бәясе туксан сумнан югарырак күтәрелде, диләр. Авыл хуҗалыгы эшләре кызган чорда ягулык бәясенең сикереше уңай йогынты ясамый, билгеле. Россиянең иң зур һава компаниясе «Аэрофлот» быелның беренче яртыеллыгында 102 миллиард сумлык зыян күргән. Үткән елның шул чорында исә 73,7 миллиард сумлык табышлы булган.

Дөнья базарында чимал бәяләре Россия файдасына түгел. Алюминийга бәя 40 процентка төште. Дөрес, нефть бәяләре кискен үсеп маташа. Россия нефте Көнбатыш куйган түшәм бәяне җимереп, барреле 70 доллардан артыкка күтәрелде. Әмма нефтьчеләр бүтән коймага килеп терәлде. Россия «кара алтын»ының төп кулланучысы булган Һиндстан аннан баш тарта. Һиндстанның нефть министры Хардип Пуни: «Безнең Россия нефтенә бәйлелегебез кискен кимеячәк», – дип белдерде. Эш шунда: бәя күтәрелгәч, индусларга элекке традицион базарлардан чимал алу отышлыракка әйләнгән. Россия экспорты кимер дигән киләчәк вәгъдә итә бу.

Рәсми каналлардан милли валютага ышаныч багламаска дигән сигналлар алына. Үзәк банк һәм Финанс министрлыгы биш ел буе ирекле пенсия тупланмалары системасы төзеделәр. Бюджет стимуллары һәм салым өстенлекләреннән файдаланса да, система эшләмәячәк. Төп сәбәбе – даими девальвация шартларында сумнарда байлык туплау файдасыз. Сумны ныгытуга юнәлтелгән чаралар күрергә була, әлбәттә. Әмма Нәбиуллина әйтүенчә, үткән елның язында эшләгән ул чаралар кыска вакытлы файда гына бирде, хәзер нәтиҗәле булмаячак.

РӘИС КӨНДӘЛЕГЕ

ХӨРМӘТЛЕ ХЕЗМӘТ

ӘЛМӘТТӘ НЕФТЬЧЕЛӘР ҺӨНӘРИ БӘЙРӘМНӘРЕН БИЛГЕЛӘП ҮТТЕ

Сәнәгать рекордлары ватаны, легендар «Ромашкино»ның әһәмияте, шәһәрне гөрләткән чаралар. Әлмәттә Нефтьчеләр көненә багышланган бәйрәм узды. Сүз уңаеннан, быел Татарстанда нефть эшкәртә башлауга 80 ел тулса, Әлмәт шәһәренә исә – 70 яшь. Бәйрәм чараларында Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов та катнашты.

Бәйрәм тантанасы тамашачыларны нефть тармагы барлыкка килгән елларга алып кайтты, Шөгер ятмасында барган эшләрне күрсәтте, «кара алтын» табуда катнашкан кешеләрнең хезмәт шартларын сурәтләде.

– 80 ел элек табылган нефть Россиянең нефть чыгару сәнәгатендә хәлиткеч роль уйнады, – диде «Татнефть» җәмгыяте генераль директоры Наил Мәганов. – Татарстанның даны бөтен илгә таралды, җитештерү рекордлары ватанына әверелде. Хәзерге вакытта легендар «Ромашкино» заманча технологияләрне сынап карау өчен мәйдан булып тора. Ышаныгыз: озак елларга җитәрлек запас бар әле.

Бәйрәм кунакларын һәм нефть эшкәртү тармагында эшләүчеләрне Рәис тә котлады.

Бәйрәм – саннарда

➤Нефтьчеләр көненә багышланган бәйрәмдә кулланылган декорацияләр **5** катлы йорт зурлыгында булган.

➤Бәйрәм быел **7** мәйданчыкта барды. Төп мәйданга **60** меңләп кеше җыелган.

➤Беренче миллиард тонна нефть **1971** елда чыгарылган, икенчесе – **1981** елда, өченчесе – **2007** елда.

– Нефть һәм газ сәнәгате ил икътисадының төп тармаклары булды һәм булачак та. Бу тармаклар – илебезнең икътисадый һәм энергетик иминлеге күрсәткече, – диде Рөстәм Миңнеханов. – Дистә еллар дәвамында тупланган тәҗрибә, югары профессионализм нефть-газ сәнәгате хезмәткәрләренә илнең ягулык-энергетика ресурсларына ихтыяҗын тәэмин итеп, алда торган максатларга ирешергә мөмкинлек бирә. Бу – авыр, әмма бик мөһим эш белән шөгыльләнүче көчле рухлы кешеләрнең бәйрәме!

Саллы хезмәт турында саннар да сөйли. Шушы еллар эчендә республикада 3,5 млрд тонна «кара алтын» чыгарылган!

– Берничә дистә ел дәвамында Татарстан нефте илнең сугыштан соңгы икътисадын торгызу, фән һәм техниканың югары казанышларын, мәгариф һәм мәдәниятне үстерү өчен нигез булып торды. Фидакарь хезмәт нәтиҗәсендә Татарстан илнең төп нефть-газ үзәкләренең берсенә әверелде, – диде Рөстәм Миңнеханов.

ДҮШӘМБЕ – ДҮШӘНБЕДӘ

Хезмәттәшлекне арттыру юнәлешләрен эзләп. Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов эш сәфәре белән Таҗикстан башкаласы Дүшәнбегә килде. Ул Таҗикстан Президенты Эмомали Рахмон белән очрашты.

– Соңгы елларда ике арадагы товар әйләнеше артса да, аның күләме аз кала. Аны арттыру буенча эшләргә кирәк, – диде Рөстәм Миңнеханов очрашу барышында. – Без, Таҗикстан Республикасы һәм Россия арасында икътисадый элемтәләрне ныгыту өчен, Таҗикстан базарында Татарстанның әйдәп баручы компанияләрен күрергә телибез.

Соңгы мәгълүматларга караганда, 2022 ел нәтиҗәләре буенча, Татарстан һәм Таҗикстанның тышкы сәүдә әйләнеше 30 миллион доллардан артып киткән. Машина төзелеше, авыл хуҗалыгы, сәламәтлек саклау кебек өстенлекле юнәлешләр буенча эш алып барылган.

Рөстәм Миңнеханов, Таҗикстанга вертолетлар, нефть химиясе продукциясе, нефть-газ җиһазлары, хәләл продукцияне китереп булыр иде, дип ассызыклады. Ул шулай ук Эмомали Рахмонга Таҗикстанда татар җәмәгатьчелегенә ярдәм иткәне өчен рәхмәт белдерде. Сүз уңаеннан, Таҗикстанда яшәүче татарлар саны 12,5 меңнән артык.

Эмомали Рахмон исә Рөстәм Миңнехановның визиты Россия белән Таҗикстан арасындагы хезмәттәшлекне ныгытуга ярдәм итәчәгенә ышаныч белдерде.

ӘРӘМ БУЛГАНЧЫ, РИЗЫК БУЛСЫН

Борчыган мәсьәлә

Халыкның кәефе әйбәт түгел, ләкин артык ыгы-зыгы да юк. Лениногорск районындагы кош фабрикасында кош гриппы чыгу сәбәпле, якын-тирә авылларда яшәүчеләрнең кәефен әнә шулай дип бәяләделәр. Узган атнада, Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов карары нигезендә, оешмадан 55 чакрым радиустагы территориягә карантин кертелде. Лениногорск шәһәре, Тимәш, Савочкино авыллары, Вәлиев бистәсендә яшәүчеләрнең дә тавык, каз-үрдәкләре юк ителергә тиешле.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Дөрес, Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсе башлыгы урынбасары Габделхак Мотыйгуллин сүзләренчә, әлегә халык арасында аңлату эшләре генә алып барганнар һәм күпчелек кеше кош-кортын ашыгыч рәвештә эшкәртергә мәҗбүр булган.

– Куркыныч тудырган зона – 5–10 километр. Без зур мәйданнарны алырга тырышмадык. Карар нигезендә, халыкның кош-кортларын юк итәргә тиешбез. Әлеге вакытта фабрикада 220 мең тавыкны һәм йомырканы яндырып бетердек, – диде Габделхак Мотыйгуллин.

Җитәкче әйтүенчә, шәхси хуҗалыклардагы кош-корт алынган очракта, кешеләргә субсидия биреләчәк. Ә менә фабрика бу акчаны алырмы-юкмы – анысы әлегә билгесез.

– Фабрикага вирусның каян кергәнлеген әйтеп булмый. Территориядә синантроп кошлар – чыпчык, карга, чәүкә, күгәрчен, саескан бик күп. Авыру тарату чыганаклары шулар булгандыр, дип уйлыйбыз. Барлык җитешсезлекләрне бетергән очракта, фабрика кабат аякка баса алачак. Әлегә вакытлыча эшсез калучылар булачак, әлбәттә, – диде ул.

Сүз уңаеннан, булган кош-кортларын эшкәртеп, туңдыргычка тутырган итләр куркыныч тудырмый, шуңа күрә аларга кагылучы булмаячак.

– Кайбер мәгълүмат чараларында кош гриппы чыгу аркасында, фермерларның эре терлекләрен дә юкка чыгарачаклар, дигән хәбәрләр таралды. Ләкин бу дөреслеккә туры килми. Монда сүз бары тик кош-корт турында гына бара, – дип тә өстәде Габделхак Мотыйгуллин.

Куркыныч янаган зонага эләккән авылларга шалтыратып, аларның да хәлен белешеп алдык. Писмән авыл җирлеге башлыгы Рәмис Насретдинов әйтүенчә, әлегә кадәр халыкның бер генә кош-кортын да мәҗбүри юк итәргә туры килмәгән.

– Куркыныч янаган зонага безнең җирлектәге бер авыл керде. Савочкино зур түгел. Якынча 90лап кеше яши. Ләкин барыбер бу хәлләр халыкны борчып алды. Мин кошлар үлү турындагы хәбәрнең беренче көннәрдә үк: «Төрле хәлләргә әзер булып торыгыз. Кош-кортларыгызны юк итәргә дә мөмкиннәр. Урамга чыгармагыз, авыру таралган очракта, бернигә дә карамастан, барысын да яндырырга туры киләчәк», – дип кисәтеп куйдым. Шуңа күрә күпчелек кеше бройлерларын да, каз-үрдәкләрен дә эшкәртеп, туңдыргычларына тутырып куйды инде, – диде ул.

Аның сүзләре буенча, күпчелек кеше хәлне аңлап кабул иткән.

– Халык өчен көтелмәгән, тиз арада хәл ителә торган мәсьәлә булса да, артык ыгы-зыгы булмады. Аңлап кабул иттеләр. Билгеле, кайбер кешеләр каз-үрдәкләрен әле иртәрәк дия-дия эшкәртте инде. Ләкин башка чара юк иде безнең – диде Рәмис Насретдинов.

Ә менә 2500ләп кеше яшәүче Тимәш авылы халкына шактый борчылырга туры килгән.

– Мин үзебезгә ашарга дип 10 баш каз алган идем. Өлгереп җитмәсәләр дә, тиз арада суеп, эшкәртергә туры килде инде. Бик кызганыч булды. Башка елларны тавыклар да ала идем. Әле ярый быел алары булмады, – диде Фәридә Абдеева.

Аның сүзләрен җирлек башлыгы да раслады.

– Фәридә хәлендәге кешеләр күп бездә, – диде Халидә Сөләйманова. – Кемдер соң гына сатарга, үзенә ашарга дип алган иде. Аларга кошларын тиз арада эшкәртергә туры килде. Әлегә кадәр аңлату эшләре алып барабыз, кешеләр һаман да эшкәртә әле. Андыйлар бетеп бара диярлек. Халык күп булса да, барысы да тавык, каз-үрдәк тотмый. Авылда якынча 1 меңләп тирәсе кош-корт бар иде.

Зөһрә САДЫЙКОВА

СОҢГЫ ЕЛЛАРДА КОШ ГРИППЫ БЕЛӘН ЗАРАРЛАНГАН ЭРЕ ХУҖАЛЫКЛАР

✓2021 ел – Яшел Үзән районының «Залесный» агрофирмасында кош гриппы чыгып, 175 мең баш күркә һәм 85 тонна кош ите юк ителде. Оешмага килгән зыян күләме 200 млн сум иде. Моннан тыш, Мөслим, Буа һәм Чүпрәле районнары фермерларына 5 млн сум зыян килде.

✓2021 ел – Тукай районында фермер Прияна Фролованың бытбылдык фермасында кош гриппы табылу сәбәпле, 50 мең кош юк ителде.

✓2017 ел – Лаеш кош комплексында 450 мең кош-корт юк ителде.

Ватык телефон

Ачыклык кертәбез

«Август азагына кадәр күпфункцияле үзәк аша биометрия мәгълүматын таратудан баш тартып гариза язмасаң, синең хакта шәхси мәгълүмат бөтен җиргә таралачак...» Август азагында әнә шундый эчтәлектәге смс-хәбәрләр ил күләмендә бик күпләрнең төн йокысын качырды. Татарстанда гына да җәйнең соңгы атнасында 18 меңләп кеше шундый гариза язу теләген белдергән. Белгечләр исә әйткән һәр сүзгә ышанмаска киңәш итә.

Казанда яшәүче эшмәкәр Раил Гафуров шикле смс-хәбәр килүгә күпфункцияле үзәккә барып гариза язган.

– Биометрия мәгълүматын, сорап та тормыйча, банклар җыйган икән, диделәр. Эшкуар булгач, көн саен диярлек кредит оешмасы юлын таптыйм мин. Дөнья хәлен белгән юк, гариза яздым. Биометрия мәгълүматы ярдәмендә сиңа кредит та, штраф та чәпеп куярга мөмкиннәр икән. Күпфункцияле үзәктә минем ишеләр шактый иде, ике сәгатькә якын чират көттем, – ди ул.

Татарстан күпфункцияле үзәге җитәкчесе Ленара Мозафарова сүзләренә караганда, социаль челтәрләрдәге биометрия мәгълүматына бәйле хәбәрләр дөреслеккә туры килми.

– Әлеге хәл гражданнарны биометрия мәгълүматы ярдәмендә танып белү турындагы федераль канун тирәсендә аңлашылмаучанлык аркасында килеп чыккан булырга мөмкин, – ди ул.

Җитәкче сүзләренә караганда, моңа кадәр бармак эзе, йөз фотосы кебек биометрия мәгълүматын эшкәртү, җыю белән банклар һәм башка шәхси оешмалар шөгыльләнгән. Хәзер исә бу эш Бердәм биометрия системасына күчә. Банклар исә август азагына кадәр үзләрендә булган мәгълүматны тапшырып бетерергә тиеш. Шунысын да әйтик, моның өчен бармак эзе хуҗасыннан рөхсәт алу мәҗбүри. Биометрияне вакытында тапшырмыйлар икән, кредит оешмаларындагы мәгълүмат юкка чыгачак.

– Гади халык исә гаризаны теләсә кайчан яза ала. Канунда моңа бәйле бернинди чикләү дә юк, – ди Ленара Мозафарова.

Тик эт чаба дип, бет чаба килеп чыкты. Танышлар, дуслар, туганнар үзара тараткан коткы аркасында, чак кына ил күләмендә күпфункцияле үзәкләрнең эше тукталып калмады. Имеш-мимешне уйлап табучылар да шуңа өметләнгәндер, бәлки. Татарстан күпфункцияле үзәгенең рәсми сайтыннан алынган мәгълүматларга караганда, августның соңгы биш эш көнендә генә дә (31 августны кертмичә) бирегә гариза язарга теләп 18 меңләп кеше мөрәҗәгать иткән. Чагыштыру өчен: июль аенда андыйлар 800 кешегә дә тулмаган.

Эльвира ВӘЛИЕВА

Көн кадагындагы 4 сорау

◆Биометрия мәгълүматы нәрсә ул?
Биометриянең төп биш төре киң таралган. Болар – бармак эзе, йөз фотосы, тавыш, күз тышчасы һәм уч төбе фотосы. Әгәр сез моңа кадәр үзегезнең шәхси мәгълүматны җыярга һәм тапшырырга язмача ризалык бирмәгәнсез һәм аны «Госуслуги. Биометрия» мобиль кушымтасына яки коммерцияле оешмага тапшырмагансыз икән, Бердәм биометрия системасында сезнең мәгълүмат, гомумән дә, була алмый.

◆Ул ни өчен кирәк?
Бердәм биометрия системасында теркәлгән мәгълүмат ярдәмендә финанс хезмәтләрне рәсмиләштерергә, электрон имза куярга, җанатар картасы алырга, Дәүләт хезмәтләре порталында теркәлү узарга мөмкин. Киләчәктә мондый биометрия кибеттә яки җәмәгать транспортында түләргә, имтихан бирергә яки нотариуска мөрәҗәгать итәргә дә мөмкинлек бирәчәк дип көтелә.

◆Бердәм биометрия системасында синең шәхси мәгълүмат бармы-юкмы икәнен ничек тикшерергә?
Моның өчен Дәүләт хезмәтләре порталына керергә кирәк. «Профиль» бүлегенә кереп, «Биометрия» төймәсенә басыгыз. Әгәр сез биометрия мәгълүматын тапшырмагансыз икән, «биометрия теркәлмәгән» дигән язу чыгачак.

◆Үз биометрияңне ничек бетерергә?
Шәхси мәгълүматтан файдалануны туктату өчен, язмача яки электрон рәвештә гариза язарга кирәк. Моны биометрия тапшырган оешмада, мәсәлән, банк бүлекчәсендә эшләргә мөмкин. Дәүләт хезмәтләре порталындагы «Биометрия» бүлекчәсе аша да гариза җибәреп була. Күпфункцияле үзәккә мөрәҗәгать иткән очракта, паспорт һәм СНИЛС сораячаклар.

ЖУРНАЛИСТ ЗӨФӘР ДӘҮЛӘТШИН:

«БЕЗНЕҢ ЕГЕТЛӘР БЕРДӘМЛЕГЕ БЕЛӘН АЕРЫЛЫП ТОРА»

ТНВ журналистлары махсус хәрби операция зонасыннан кайтты. Ватан сагындагы якташларның хәлен белешергә дип дүртенче мәртәбә сәфәр кылган журналист Зөфәр ДӘҮЛӘТШИН белән ярдәм, ышаныч һәм өмет турында әңгәмә кордык.

:: Зөфәр, махсус хәрби операция (МХО) зонасына беренче генә баруыгыз түгел. Бу сәфәр башкаларыннан кай ягы белән аерыла?

– Беренче тапкыр узган елның декабрендә бардык. Быел апрельдә, июльдә һәм менә август ахырында сәфәр кылдык. Монысында андагы хәлләр «кызурак» тоелды. Тизрәк йөрергә, игътибарлырак булырга туры килде. «Алга» һәм «Тимер» батальонындагы егетләр янына барган идек. Сөйләшә генә башладык, безнең яктан ата башладылар. Бер урында озак торырга ярамый. Чөнки каршы як та җавап бирәчәк.

Беренче барганда кая барганыбызны белмибез, нindидер билгесезлек, яшермим, курку да бар иде. ТНВ безгә кием, газ плитәсе, йокы капчыгы, чатыр – нәрсә кирәк барысын да төяп җибәрде. Махсус «УАЗ» машинасы сатып алдылар. Шөкер, бер тапкыр да көйсезләнмәде. Беренчесендә МХОга үз теләге белән чыгып киткән «Алга» батальонындагы егетләр белән генә очраштык. Соңгы баруларыбызда исә мобилизацияләнгән якташларыбызның да хәлен белештек. Аңлыйсыздыр инде, без теләгәнчә генә килеп чыкмый. Кемдер башка урынга күчкән була, кемдер элемтәгә чыкмый.

:: Узган елдан бирле йөрисез. Егетләрнең кәефе үзгәрәме?

– Барысының да җиңү яулап, тизрәк өйләренә кайтасылары килә. Яшермим, арыганнар, әмма өметләре сүрелми. Хәтта яраланган егетләр дә, тизрәк савыгып, кабат МХО зонасына юл ала. Кайберләре хәтта өйләренә кайтып та китми. Чын ир-егетләр инде. Ни эшләгәннәрен яхшы беләләр. Безнең туган якта мондагы хәлләр кабатланмасын, диләр.

Әйе, баштарак егетләргә тагын да авыррак иде. Шул ук азык-төлек, кием-салым белән тәэмин итүдә җитешсезлекләр булды. Хәзер исә андый проблема юк дип беләм. Система җайга салынган. Татарстанның да нинди ярдәм күрсәткәнен күреп торабыз бит. Шөкер, элемтә бар, күчтәнәчләр барып җитә. Башка төбәк егетләре хәтта безнекеләргә көнләшеп тә карый. Тушенка белән оекбаш кына түгел, махсус җиһазлар да, хәтта күчереп йөртелә торган мунча алып баралар. Татарлар бит инде, безнекеләр җир астында да, өстендә дә – кайда мөмкинлек бар, шунда мунча ясый икән. Кул астында нәрсә бар, шуннан юыну урыны корып куялар. Алар әйткәч, без дә игътибар иттек: ул якларда авылларда мунча юк икән. Безнекеләргә хәтта җирле халык та шакката.

:: Егетләр уртак бурыч өчен туган якта да зур эш башкарылганын аңлыймы?

– Әлбәттә, аңлыйлар һәм үзләренә күрсәтелгән ярдәмне тоялар. Аларга әйберләр генә түгел, рухи теләктәшлек һәм үзләрен онытмау да кирәк. Бу барганда дәүләт бүләкләре тапшырдык. Командирлары әйтүенчә, егетләрнең барысы да игътибарга лаек. Алар үзләре дә, Татарстаннан килеп, хәлләрен белешүче булганга сөенә.

> Безнең егетләр бердәмлеге белән аерылып тора. Татарстан әләмен күргәч, күпмедер дәрәҗәдә гаҗәп тә, җанга да рәхәт. Херсон өлкәсендә юл күрсәткечендә Казан белән Мамадышның да кай якта икәнен язып куйганнар. Безнең егетләр кайда да югалып калмый! Кайберләре белән берничә тапкыр очраштык, дуслашып беттек инде. Аллаһка шөкер, күбесе исән-сау. Әмма, кызганыч, югалтулар да бар.

:: Җирле халыкның хәле ничек?

– Россиянең яңа төбәкләре – Херсон һәм Запорожье өлкәләрен, Донецк һәм Луганск республикаларының барысын да йөреп чыктык. Декабрьдә барганда Мариуполь котчыккыч хәлдә иде. Йортлар корымга баткан, диварлары тишелеп беткән. Икенче тапкырында матур йортлар салынган яңа микрорайон күрдек. Дошманнан азат ителүгә үк юллар төзи башлыйлар. Лисичанскида да зур үзгәрешләр булып ята. Урамда халык күбрәк булуына игътибар иттек. Базарлар, кибетләр эшли. Декабрьдә ут та, газ да, су да, җылы да юк иде. Лисичанскида су өләшә торган урында бер хатын белән сөйләшеп тордык. Биредә яшәдем һәм, ни генә булмасын, беркая да китмәячәкмен, ди. Суны аерым вакытта гына алып киләләр. Элемтә юк. Мәктәпләр эшләми, һич югы аралашсыннар дип, балаларны түгәрәкләргә йөртәләр. Чөнки курkудан арыганнар инде. Халык акрынлап тыныч тормышка ияләшә. Хәзер инде анда Татарстанны да беләләр. Хәтта әбиләр дә: «Безгә ярдәм итәсез, сездән башка ни эшләр идек. 4 ай буе мәктәп подвалында яшәдек. Хәзер ашаталар да, эчертәләр дә», – дип шөкер итәләр. Без килгәндә, Рубежноедагы балаларны Татарстандагы лагерьга җибәрергә әзерлиләр иде. Казанны күреп белмәсәләр дә, аның каравы бик матур шәһәр икәнен ишеткәннәр.

Зөфәр Дәүләтшинның шәхси архивыннан

ТНВ журналистлары Ватанны сакларга киткән егетләр белән аларның якыннары арасында элемтә өзелмәсен дип тырыша.

:: Ялгышмасам, кайсыдыр сәфәрдән кайткач, куркыныч булса да, кабат барырга теләгәнегезне әйткән идегез. Нәрсә тарта?

– Әнә шул егетләр, Ватан сакчылары тарта. Аларның күзләренә карап, кәефләрен күргәч, эшебезнең нәтиҗәсен сизәбез. Димәк, юкка тырышмыйбыз. Үзебезне егетләр һәм аларның якыннары арасындагы күпер дип саныйбыз. Андагы хәлләрне күреп кайткач, тормышның кадерен яхшырак аңлый башлыйсың. Иртән торабыз, кояш балкый. Тыныч кына эшкә барып кайтасыбызны беләбез. Ә аларда андый ышаныч юк, бер мизгелдән ни буласы билгесез. Кич яткач, иртән уянып булырмы? Иртән торгач, кичкә кадәр яшәп булырмы? Хәтта гади халык та кайсы яктан атканнарын чамалап, ничек сакланырга кирәклеген белә. Әнә шуларны ишеткәч, хәтта моңарчы игътибар итмәгән вак-төяк тә кадерле була башлый.

Якташларыбыз янына тагын барачакбыз. Җиңү яулап кайтканчы, хәлләрен белешеп торачакбыз.

:: Алайса, мондый сәфәрләрегез азрак булсын!

– Мин дә егетләргә шулай дим: тиз арада исән-имин туган якта очрашырга насыйп булсын!

Әңгәмәдәш – Илнар ХӨСНУЛЛИН

«Иң мөһиме – ярату»

РОССИЯ ГЕРОЙЛАРЫ УКУЧЫЛАР БЕЛӘН ОЧРАШТЫ

Белем көнендә Казанның 187 нче күппрофильле лицеенда батырлык дәресләре үтте. Мәктәп укучылары Россия Геройлары Марат Алыков һәм Александр Борисевич белән аралашты.

Россия Герое, Әфган сугышында катнашкан очучы-сынаучы Марат Алыков кадет сыйныфы белән очрашты. Ул укучыларга яхшы укуларын теләде һәм армиядә хезмәт итү турында яхшылап уйларга киңәш итте.

– Армия ул – яшәү рәвеше, хәрби хезмәткә тулысынча бирелергә кирәк. Шуңа күрә бу аңлы сайлау булырга тиеш, – диде Россия Герое. – Сез – яшьләр, әлбәттә, укудан тыш, башка нәрсәләр белән дә шөгыльләнергә телисез. Минем тормыш тәҗрибәмә ышаныгыз: белемнәрне яхшырак үзләштерсәгез, тормышыгыз җиңелрәк булачак. Әмма тормышта бер нәрсә дә идеаль булмый. Сезгә җитди карарлар кабул итәргә туры киләчәк. Хаталар ясарга курыкмагыз. Иң мөһиме – ул хаталарны төзәтергә һәм киләчәктә аларны булдырмаска. Тормышыгызны очу белән бәйләсәгез, мин бәхетле булыр идем. Берәрегез очучы-сынаучы булса, икеләтә шат булырмын. Сез – безнең киләчәгебез. Сез әтиләребез һәм бабаларыбыз яулаган казанышларны саклап калырга тиешсез. Әгәр үзегездә максатчанлык, стресска каршы тору, яхшы физик әзерлек кебек сыйфатлар тәрбиялисез икән, һәр очрактан җиңүче булып чыгачаксыз. Экстремаль хәлләрдә барысын да салкын акыл һәм кайнар йөрәк белән эш итәргә кирәк.

Александр Борисевич 11 нче сыйныф укучылары белән очрашуда Беренче Чечня кампаниясендә күрсәткән батырлыгы турында сөйләде. Мәктәпне тәмамлаганда мөһим карар кабул итү турында сөйләгәндә, ул хәрбиләр династиясен дәвам итмәгән улын мисал итеп китерде. «Үзең сайлаган юл – иң бәхетлесе», – диде Россия Герое.

– Хәзерге вакытта Россиядә 614 Герой исән, һәр көнне яңалары өстәлеп тора. «Алеша» танкы экипажындагы якташыгызны гына алыйк. Аның белән очрашуыбызга бик шатмын. Махсус хәрби операциядә Татарстан җиңүгә җитди өлеш кертә, – диде Александр Борисевич.

Ләйсән САФИНА

Ватан хакына

ЙӨРӘК ҖЫЛЫСЫН КУШЫП...

Барысы да егетләр өчен! Махсус хәрби операциядәгеләргә челтәр үрүчеләр дә, мунча ясаучылар да, күчтәнәч ташучылар да әнә шулай ди. Берәү дә әйтеп эшләтми үзләрен. Йөрәкләре кушканга эшли алар.

Мамадыш мунчасы...

Мамадышта яшәүче 63 яшьлек Юрис Шәкүров җылы сүзләрне еш ишетә. Гомере буе кешеләргә гел игелек эшләгән Юрис абый илгә килгән хәсрәтне дә үзенчә җиңеләйтергә тырыша. Ул егетләргә мунча ясый башлый.

– Башыма шундый уй килгәч, бу хакта район башлыгы Анатолий Ивановка әйттем. Мин килгәндә, хакимият бинасында махсус хәрби операциядә катнашучы егетләргә ярдәм итү турында сөйләшәләр иде. «Каян белеп килдең?» – диештеләр. Йөрәк кушты. Апрель ае иде ул. Районыбызда ярдәм чараларын оештырып йөрүче Фәнил Гыйззәтуллин белән киңәшеп, мин эшкә тотындым. Иганәчеләр ярдәме белән, икенче көнне үк йортыбыз каршына ике прицеп алып килеп бирделәр, – дип сөйли Юрис абый.

«Ил төкерсә, күл була», – диләр бит әле. Юрис абыйның мунча ясаячагын белеп алган эшмәкәрләр барысы да ярдәм итәргә ашыга. Берәү дә каршы килми. Көнендә үк материал биреп җибәрүчеләр, акча бирүчеләр дә була.

– Материалы булгач, эшләүнең бер авырлыгы юк аның. Өч улым бар. Алар да, әйдә булышабыз, әти, дип кенә торалар. Гаиләм бу эшемне бик хуплый, – ди Юрис абый. – Беренче мунчаны Фәнил машинага тагып алып та китте инде. Менә икенчесен ясап бетердем. Өченчесенең бар кирәк-ярагы әзер. Кирәк икән, 10ны да, 20не дә ясап бирә алам.

«Сезнең челтәр коткара»

Кукмара районының Өркеш авылында яшәүчеләр икенче елын инде махсус хәрби операциядәгеләргә маскировка челтәре үрә. Фирая Мортазина оештыра бу эшне.

– Мин башта мәдәният йортында эшләдем. Лаеклы ялга чыккач та, файдабыз тисен, дидем. Авылдашлар өчен «Ватсап»та төркем булдырдым да, кул эшләренә тотындык. Башта кыш буе оекбаш бәйләдек, аннары челтәр үрә башладык. Кеше яшәмәгән йортларның коймаларына кадак кагып, эшкә тотындык, – дип сөйли Фирая апа. – Шуны әйтәсем килә: авылдашларым бик ярдәмчел. Берәү дә каршы килми, ничек тә ярдәм итәргә ашыга. Үзебезнең ике авылдашыбыз, киявем дә Ватанны сакларга китте бит. Ни йөрәгең белән тик ятарга кирәк? Андагы һәр солдат – кемнеңдер газиз баласы.

Бу эшкә 20гә якын хатын-кыз кушылган. Өркеш хатын-кызлары солдатларга барлыгы 18 челтәр үргән.

– Әле менә кирәк-яраклар җыйдык. Һәр кеше нидер китерә. Бик күп азык-төлек төяп җибәрдек инде. Махсус хәрби операциядән кайткан ике якташыбыз авылга килделәр. Сез үргән челтәр ярдәме белән исән калабыз, диләр. Рәхмәт әйтәләр. Бу сүзләр безне тагын да ныграк рухландырды, – ди Фирая апа.

Егетләргә – 20 машина

«Боевое братство» бөтенроссия оешмасының Нурлат бүлеге егетләре МХО зонасына инде 15 тапкыр барып кайткан.

– Баштарак үзебезчә кирәк-ярак җыйган идек. Соңрак егетләрне күреп сөйләшкәч, аларга ни кирәк, шуны алып бара башладык. Безнең төркем анда 15 тапкыр барып кайтты, – ди «Боевое братство» бөтенроссия оешмасының Нурлат бүлеге вәкиле Владислав. – Без Фирзәр Тямаев белән бергә эшлибез. Иң авыр чакларда Фирзәрнең абыйсы, Татарстанның атказанган артисты Фирдүс Тямаев ярдәм кулы сузды. Ул чакта булышырга теләк бар – акча юк. Менә шунда Фирдүс акчасын да бирде, машинасын да тапты. Без инде егетләргә 20 нче машинабызны илтәчәкбез.

Владислав, анда барган саен, тормышка шөкер итеп кайтабыз, ди.

– Монда без рәхәттә яшибез, ә анда егетләр көн дә үлем белән очраша. Нурлат егетләре өчен генә ярдәм илтмибез, Татарстан егетләре булган һәр полкка барып җитәбез. Без бердәм, тату, дус булырга тиеш. Авыр чакта ярдәмләшеп яшик. Егетләргә булышкан һәр кешегә рәхмәтлебез, – ди Владислав.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

КАЙГЫ УРТАКЛАШУ

«Татмелиорация» системасына керүче барлык мелиораторлар коллективы, бертуганы **НОТФУЛЛИН Йосыф Гайсә улы** вафат булу сәбәпле, «Татмелиорация» траст компаниясе» ачык акционерлык җәмгыяте генераль директорының финанс мәсьәләләре буенча урынбасары – җәмгыятьнең баш бухгалтеры Нотфуллин Мансур Гайсә улының авыр кайгысын уртаклаша.

ҖИДЕНЧЕ КАТТАН КАРАШ

Наил ШӘРИФУЛЛИН

Яктылык өләшүчеләр

Андый мизгелләр хәтергә гомерлеккә уела. Ярты гасырдан артыграк вакыт узса да, беренче кат мәктәп бусагасын атлап кергәнемне дә, беренче укытучым Сәлимә апаның елмаюлы йөзен, әйткән сүзләрен дә яхшы хәтерлим әле. Әнкәй белән без ни сәбәпледер ул көнне соңгарак калдык. Кырыктан артык бала – ике параллель сыйныфның икесе дә инде классларга кергән, парталар артына утырган иде. «Зыян юк, дәрескә беркайчан да соңга калмаячаксың, шулай бит». Укытучым хәтта исемемне атады. Безне хәреф танырга, язарга, укырга, санарга өйрәткән укытучы ападан ишеткән беренче сүзләр...

1 сентябрь гадәттә укучылар бәйрәме буларак кабул ителә. Укытучы читтәрәк кала. Әйдәгез, алар турында сөйләшик. Татарча тәрҗемәгә авыррак бирелә торган шундый сүзләр бар бит: «Сеять разумное, доброе, вечное». Аның кемгә кагылганы барыбызга да билгеле. Күптин-күп төрле башка һөнәр ияләре хакында тирән мәгънәгә ия андый сүзләр юк та кебек. Була да алмыйдыр. Укытучы ул – чын мәгънәсендә илаһи зат, яктылык өләшүче, мәгърифәт нуры таратучы. Аның хезмәте дөньяны әле белмәгән, аңламаган балага барын да төшендеру, фәннәрне өйрәтүгә генә кайтып калмый. Укытучы – адәм баласыннан кеше, гражданин, җәмгыятьнең лаеклы вәкиле ясарга алынган зат. Мәрмәр кисәген айлар буе чокып, соңыннан шуннан матур сын китерен чыгарган скульптор кебек ул. Үзе укыткан балаларның тормышта үз урынын табуын, уңышларга ирешүен теләмәгән, шуның өчен җан атмаган укытучы дөньяда юк. Һәр мәрмәр таштан чын сәнгать әсәре, матурлык чыгу-чыкмау – анысы башка мәсьәлә: ташның, чималның да төрлесе була бит.

Укытучы – илнең, җәмгыятьнең килачәген тәэмин итүче, иртәгесен билгеләүче һөнәр, дисәк, һәркем килешер. Киләчәк – алар кулында. Бәс шулай икән, укытучы һөнәре иң абруйлы, иң югары хезмәт хакы алып эшләүче һөнәрләр арасында торырга тиеш түгел микән? Андый очракта шул ук педагогик вузларга да олы конкурслар булыр – килер буын, аның белем дәрәҗәсе, тәрбиясе, сыйфаты өчен үз өстенә җаваплылык алырга әзер кешеләр иң-иннәр арасыннан сайланыр иде. Бүгенгә андый хәл күзәтелми. Август аенда үткән традицион киңәшмәдә республика мәктәпләренә 2000 укытучы җитмәве әйтелде. Кадрлар дигәндә ил буенча да хәл бер дә куана торган түгел. Сәбәпләр арасында иң беренчесе, әлбәттә инде, алда әйткән хезмәт хакы. Педагогикадан, мәгариф системасыннан ерак кеше булсам да, чамалыйм: укытучы хезмәте бүгенгедән ике тапкыр югарырак бәяләнергә, алар ким дигәндә ике тапкыр күбрәк алырга тиеш. Бу шарт үтәлгәндә кадрлар кытлыгының эзе дә калмаячак. Ул гына да түгел, мәктәпләрдә укучыны авызына гына каратып тотканнар, үз эшенең осталары, күзләре янып дәрес биргәннәр саны артачак. Болар тормышка ашканда, белемгә, фәннәргә мәхәббәте дөрләп кабынган балалар күбәячәкә дә шик калмый. Скульптор сәләтлерәк булган саен затлы сыннарның артуы табигый. Тәрбиялелек дәрәҗәсе дә башка булачак. Саналган шартлар исә, ахыр килеп, төп казанышка – илдә фән, технологияләр, җитештерү өлкәсе генә түгел, бөтен тармакларның да алга китүенә, үсеш-алгарышка юл ача.

Шунысын да билгелисе килә: укытучылык, белем, тәрбия бирү ул – иҗат. Аерма шунда: укытучы иҗаты рәссам, композитор, язучы иҗатынан катлаулырак, авыррак. Чөнки ул укучысына әдәби әсәр, көй яисә сурәт, төсләр аша тәэсир итми, алар аша тәрбия бирми, ул турыдан-туры эшли. Укытучы укучы алдында шәхес булып, балаларны үзе мисалында, үзе укыткан фәнгә мәхәббәте, үзенең дөньяга карашы, эрудициясе аша тәрбияли икән, белем бирү системасында барысы да үз урынында дигән сүз.

Укытучы, миңа калса, әле тагын үз караш, инануларында азат, ирекле дә булырга тиештер. Шул ук иҗат кешеләре – шагыйрь, рәссам, язучы кебек. Кайдандыр тәшерелгән күрсәтмәләр, идеологик кысалар аны чикли, ирексез итә, аның потенциалын кимета. Кырыкмага кырык төрле отчетлар хакында гомумән әйткән дә юк. Укытучы үзе ирекле булганда гына ирекле кеше, шәхес тәрбияли ала. Шул чагында гына ул, кайсы фәнне – математиканы ул, физика, химия, тарихныны укытуына карамастан, рухи остаз була. Кешелеклелек, тәрбиягә, хезмәткә мәхәббәтне, дөньяга дөрес карашны теләсә кайсы фән аша тәрбияләп була бит.

Бүген укытучының җәмгыятьтәге роле хакында төрле дискуссияләргә кереп китеп, аңа «мәгълүмат ырындагы навигатор», «хезмәт күрсәтүче», «нәтиҗәле менеджер», башка исемнәр тагарга туры түгел, ул һөнәрнең асылын үзгәртергә тырышулар да күзәтелә. Тик заманына карамастан, «белем һәм тәрбия» дигән симбиоз үзгәрмәскә, урынында калырга тиештер. Чөнки беләбез: белемле тәрбиясезләрдән кайчак албастылар да ярала.

Абруй, дәрәҗә дигәннән. Без мәктәптә укыган заманнарда укытучының абруе бик тә югары иде. Укучылы әйткән да юк, эти-әниләр дә гыйлем биручелә затка олы хөрмәт, соклану аша карады. Соңгысы – үтә дә дөрес һәм кирәкле шарт. Биредә тагын алда әйтелгән нәтиҗәгә, дәресгә, шуңа өстәмәгә килеп төртеләбез: эти-әни, җәмгыять укытучыга хәерхаһлы, ихтирамлы булмаганда, белем системасы камил була, тозек эшли, матур нәтиҗәләргә китерә алмыйдыр ул...

Бу юллар авторына белем биргән укытучыларның барысы да диярлек бакыйлыкта инде. Урыннары җәннәтнең иң түрендә булсын аларның. Һич арттырмый әйтәм, алар барысы да без – укучыларның тормыш юлларын озак еллар буе яктыртан, дөрес юл күрсәткән маяк булдылар. Мәктәпкә һәрдаим теләп кенә түгел, сөенеп баруымны, фәннәрнең күбесенә гашыйклыгымны мин фәкать безне укыткан укытучыларның үз эшен һәм безгә – укучыларны яратуына, аларның фидакарьлеге, затлылыгына гына бәйлим. Укытучы минем өчен изгедән изге, гүзәлдән гүзәл зат булды һәм шулай булып калачак та.

Илдар Мөхәммәтҗанов

ТИМӘСЕН ЧИР!

Алдан аяк киенер чак! Белгечләр вируслы чирләр баш калкыткан көзге чорда шушы кагыйдәне истә тотарга чакыра. Ел саен бу чорда ОРВИ, грипп белән авыручылар саны артуга ияләшеп беттек инде. Соңгы елларда алар сафына коронавирус та өстәлде. Бу атналарда исә республикада ковид йоктыручылар саны янә арта башлады. Чаң сугарга кирәкме? Бакча эшләре вакытында нинди чирләрдән сакланырга? Журналистлар белән очрашуда бер төркем белгеч шул уңайдан киңәшләрен бирде.

Үпкә янә сынала

Күпмедер вакыт онытылып торган коронавирус тормышыбызга янә әйләнеп кайтырга мөмкин. Белгечләр шулай дип фаразлый. Татарстан буенча Роспотребнадзор идарәсе җитәкчесе урынбасары Любовь Авдонина сүзләренә караганда, соңгы арада республикада теркәлгән саннар да бу фаразларның рас килүенә ишарәли.

– ОРВИ һәм грипп сезоны якынлаша. Билгеле булганча, коронавирус та ОРВИ төркемендәге авырулар рәтенә керә. Шуңа күрә якын арада аны йоктыручылар саны да артыр дип фаразлыйбыз, – диде Любовь Авдонина.

Әлегә вазгыять торгрыклы булып кала бирә. Узган атнада Татарстанда 51 кешегә «коронавирус» диагнозы куелган. Аннан алдагы атнада да шул чама кеше ковид йоктырган булган. Ел башыннан бирле исә 13603 кешедә коронавирус ачыкланган. Әлегә башка вируслы авыруларга бәйле вазгыять тә тотрыклы. Узган атнада республикада ОРВИ һәм грипп йоктыруның 6638 очрагы теркәлгән.

Белгечләр яшерми: вазгыять барыбер үзгәрәчәк. Шул ук коронавирус, ОРВИ, грипп белән авыручылар саны да артачак. Шуңа күрә алдан аяк киенергә киңәш итә алар. Бүген республика хастаханәләре күпләп битлек, дару, кирәк-ярак белән тәэмин ителгән. ИВЛ аппаратлары да әзер тора. Белгечләр, аларның да кирәге чыкмагае, ди. Ник дигәндә, соңгы арада коронавирус кабат пневмония рәвешендә уза башлаган.

– Моңа кадәр 98 процент очракта ковид гадәти ОРВИ кебек яки бернинди билгеләрсез уза, дип сөйли идек. Узган атнада коронавирус йоктыручылар арасында пневмония очраклары да ачыклана башлады. Коронавирус белән авыручыларның 12 процентын тәшкил итә ул. Чагыштыру өчен: аннан алдагы атнада коронавирусны үпкә ялкынсыну рәвешендә уздыручылар нибары 2 процентны гына тәшкил итә иде, – ди Любовь Авдонина.

Республикадагы ковид госпитальләрендә дә хәлләр мөшкелләнә башлаган инде. Бүген биредәге 252 ятак урыннарның нибары 10 проценты гына буш икән. Татарстан Сәламәтлек саклау министрлыгының штаттан тыш баш эпидемиологы Дмитрий Лопушев сүзләренә караганда, биредә, нигездә, коронавирусны авыр формада кичерүчеләр ята. Вазгыять катлауланa калса, госпитальләргә өстәмә ятак урыннар куячаклар.

– Вируслы чирләрдән саклану өчен вакцина ясатудан да яхшысы юк. Моны хәзер үк эшләргә мөмкин. Татарстанга гриппка каршы 642690 доза «Совигрипп», «Ультрикс квадри» вакциналары кайтты. Аларны 2,4 миллион кеше ясатыр дип көтелә. Бу – республика халкының 60 проценты дигән сүз, – ди Татарстанның баш эпидемиологы.

Вирусны чирләр белән бергә тормышыбызга коронавирус котырган чорда гамәлдә булган кайбер чикләү чаралары да әйләнеп кайта. Аерым алганда, хәзер оешма җитәкчеләре эшкә керер алдыннан хезмәткәрләрнең температурасын тикшерә башларга тиеш булачак. Күптән түгел Россиянең баш санитар табибы Анна Попова шул хакта карар чыгарды.

Бу эш мәктәпләрдә дә көчәйтеләчәк. Мәктәп бусагасын атлап керер алдыннан укучы, укытучыларның тән температурасын да тикшерәчәкләр. «Температурасы күтәрелгән кеше, мәктәпкә кереп, чир таратып йөрерлек булмасын», – дип искәртте Любовь Авдонина.

Тычкан да сагалый

Вируслы авырулар баш калкытып килә, җәй буе куркытып торган инфекциясе чирләр исә акрынлап кире чигенә. Республикада җәй башында тынычлыкны алган кызамык йөктыру очраклары кимегән. Ел башыннан бирле республикада 92 кеше кызамык йөктырган. Шуларның 43е – балалар. Хәтерләсәгез, кызамык таралу турында беренче хәбәрләр быелның февраль аенда ук ишетелә башлады.

– Хәзер вазгыять тотрыкланды. Кызамыкка каршы иммунлаштыру тәмамланды. Дөрес, планлы прививкалар әле дә ясала. Кызамык – яшен тизлегендә тарала торган авыру. Шуңа күрә аңа каршы вакцина ясату бик мөһим, – дип ассызыклады Любовь Авдонина.

Бәрәңге алу, уңыш җыю, бакчаларны чистарту белән үрелеп барган чорга аяк бастык. Елның-елында бу чорда тычкан бизгәге йоктыру очраклары да арта. Шуңа күрә белгечләр быел да уяулыкны югалтмаска чакыра. Бүген республикада тычкан бизгәге йоктыруның 539 очрагы исәпләнә. Бу узган елның шул ук чоры белән чагыштырганда ике тапкыр күбрәк.

– Әлеге чирне, нигездә, кыр тычканнары тарата. Алар авыру тычканның төкерегe, тизәк-бәвеле аткан теләсә кайсы җиргә кагылуга ук йогарга мөмкин. Шуңа күрә сарай, бакчада эшләгәндә, учакка утын җыйганда, салам өйгәндә аеруча игътибарлы булырга кирәк. Ашар алдыннан кулларны яхшылап юарга да онытмагыз, – дип кисәтә белгечләр.

Любовь Авдонина сүзләренә караганда, хәзерге вакытта авыру тычканнар ачыкланган бөтен мәйданчыклар эшкәртелгән. Талпаннарга бәйле вазгыять тә тотрыкланган. Хәтерләсәгез, иртә язда аеруча активлашкан иде алар. Җәйге челлә исә талпаннарны куркыткан. Яз башыннан бирле республикада талпан кадалуның 7,6 мең очрагы теркәлгән. Бу узган елның шул ук чоры белән чагыштырганда 7 процентка азрак.

– Хәзер бездә талпаннар өчен янә уңай шартлар саклана. Шуңа күрә август – сентябрь аралыгында алар кабат актив рәвештә һөҗүм итә башларга мөмкин. Шуңа күрә алардан зыян күрүчеләр саны артыр дип фаразлыйбыз, – диде Любовь Авдонина.

Билгеле булганча, талпаннар боррелиоз, энцефалит кебек җитди чирләр дә тарата. Быел республикада 32 кеше талпаннар аркасында – боррелиоз, 4 кеше энцефалит йоктырган. Билгеле булганча, әлеге чирләр баш миенә зур зыян сала. Шул рәвешле көзен мул уңыш белән бәрәнтән чирләрне дә мулдан җыймас өчен уяулыкны югалтмаска кирәк, дип кисәтә белгечләр.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

КОТЛЫЙБЫЗ!

2 сентябрьдә «ВТ» газетасының яшь, талантлы журналисты **Лилия ГЫЙМАЗОВА** сөйгәне **Илнар** белән гаилә корды.

Парлы гомерегезнең тәүге уртак бәйрәме белән тәбриклибез!

Вәгъдәләр бирешкәнсез икән, гомерегезнең соңгы сулышына кадәр аңа тугры булсагыз иде. Гаилә булгач, бүгеннән барысы да уртак сезнең: шатлык-куанычлар да, моң-зарлар да, югалту-табышлар да! Шуңа күрә сөюегезне кадерләгез, саклагыз!

Бәхет касәгез тулы, тормыш юлыгыз сикалтәсез, мәхәббәтегез гомерлек булсын, яшьләр! Гаиләгезгә кайгы-хәсрәт җиле кермәсен, ике арадагы кайнар хисләр сүрелмәсен! Парлы гомерегездә сөенечле мизгелләрегез күп булсын!

Иң изге теләкләр белән,
«ВТ» редакциясе коллективы

АЧЫЛГАНЧЫ КИРӘК, Ә АЧЫЛГАЧ...

Мөнәсәбәт

Быелгы Белем бәйрәме көннәрендә Балтач районының Алан авылында өр-яңа мәктәп-бакча комплексы, Нормадагы һөнәри көллият филиалы исә, капиталь ремонттан соң танымаслык булып үзгәреп, укучылар кабул итте. Болар икесе дә бик күптән көтелгән тәзелешләр иде, шуңа күрә икесе дә районда яшәүчеләр өчен зур вакыйга булды.

Минем үземә бу яңалыкларга тулысынча сөенергә берничә сәбәп комачаулады. Беренчедән, көллиятнең дәрәҗәле, укырга тирә-як районнардан да балалар күпләп килгән чакларын әйбәт беләм. Аның филиал булып калуы бер чордагы җитәкчеләрнең битарафлыгы сәбәпле генә булды. Филиал булып калуы исә бик күп мөмкинлекләрне чикләде. Югалганнарны кире кайтару өчен шактый еллар кирәк булды һәм әле дә нык тырышырга туры киләчәк. Теге елларда күршеләр йоклап ятмады шул, бүген көндәшлек шактый көчле инде. Яңартылган уку йорты, яңа шартлар бу юлда зур ярдәм булыр дип ышанасы килә.

Аланлылар өчен шатлансам да (авылда моннан ун еллап элек өр-яңа мәдәният йорты ачылган иде инде), социаль челтәрләрдә күренгән бер мәгълүмат тагын уйланырга мәҗбүр итте. Баксаң, быел районда беренче сыйныфка 334 бала укырга керә икән, ике мәктәпкә, алты мәктәп-бакча комплексына (!) беренче сыйныфка укырга керүче балалар юк. Алар арасында соңгы елларда гына төзелгән өч заманча мәктәп-бакча комплекслары булу күңелне аеруча әрнетте. Уйланмас җирдән уйланырсың...

Төзелмәсә, авылда ул юк, бу юк, дибез. Күпләр яшьләрнең авылда калмау сәбәбен дә уйаймы, заманча балалар бакчасы, мәктәбе, клубы булмауда күрә. Алар да, күрәсең, төзелгәнче генә кирәк. Укырга керергә баласы булмаган авылларда аларны нинди язмыш көтә? Менә риторик сорау кайда. Ә бит аларның саны алга таба да артачак кына әле. Күңелсез фараз, тик авыллар көнләп, сәгатьләп картая. Әле генә шаулап торган авылларда яшьләр, балалар азая. Шул ук вакытта берни дә төзелмәсә, яңартылмаса, бу авылларның картаюын, улемен тагын да тизләтер иде. Программалар шул яклап бик әйбәт, тик алар берничә дистә елга соңарды, миңа калса. Колхозлар һәр авылга үз хисабына мәктәп, бакча, клуб, кибетләрне ул чакта тикмәгә төземәде шул. Менә шушы «чылбыр»ны өзмәскә, дәвам итәргә кирәк иде дә...

Бер чорда авылларда мәктәпләр, балалар бакчалары ябу, берләштерү башланган, без, авылныкылар, аны бик авыр кабул иткән идек. Күрәшеп, даулашып йөргән авыллар да, битараф кына ризалашучылар да булды. Ул чакта безне аларның барысының да вакытлыча гына ябылуына ышандырырга тырышканнар иде. Күпләр ышанмады. Хәзер инде ябылган бер генә бинаның да ачылып, элекке куәт белән эшләп китә алмавына үз күзләребез белән ышандык. Ябылмаган булса, быел авылыбызда типовой балалар бакчасы мәктәп ачыланга, киләсе елга шулай ук колхоз көче белән төзелгән, шундый ук типовой клуб ачылуга илле ел тулган булыр иде. Инде ябылганнарына дистә елдан артык, берничә ел элек сүтеп үк аттылар. Кырык еллап балаларга белем биргән мәктәбебездә шул дәвердә бары бер генә тапкыр (анысы да соңгы яктa – 2004 елда гына) беренче сыйныфка укырга керүче булмады. Безнең чорда ел саен 6–7 бала укырга керсә, соңгы елларда өчәр, дүртәр бала укырга керү табигый иде. Инде дистә елдан артык балаларны күрше Салавыч лицеена автобус йөртә. Уңай яклары да бар, билгеле. Тик мәктәпсез, клубсыз авыллар да бик күңелсез. Тагын да күңелсезе – бездә инде алар кабат төзелмәячәк...

Бер ябылган бинадар кабат ачылмый – монысы бәхәссез. Әле авылында мәктәбе, клубы-мәдәният йорты эшләп торган авылларда яшәүчеләр моны исләрендә тотсын, ябылу хәлен җиткермәс өчен тырышсын иде. Аларны төзү, ачу – җитәкчеләр эше, алар вазифасы. Ә аларны саклау, яшәтү дигәне бездән тора. Анысы нидер төзүгә караганда да авыррак, катлаулырак. Авылларыбыз элеккечә гөрләп торсын өчен аңыбызда, тормышыбызда әле тагын бик күп үзгәрешләр кирәк шул...

Гөлсинә ХӘБИБУЛЛИНА

Белемгә юл

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

Авылларда яңа мәктәпләр ачу – үзе бер вакыйга. Тукай районының Шилнәбаш мәктәбе директоры Татьяна Калугина да шулай ди.

– Искесе 96 укучыга гына исәпләнгән иде. Безнең авыл шәһәргә якын. Шуңа күрә балалар саны арта бара. Быел 1 нче сыйныфка 15 бала укырга килде. Былтыр барлыгы 176 бала белем алды. Кабинетлар җитми иде. Икенче смена ясамадык анысы. Укытучылар, директор булмәләрен уку сыйныфлары итеп үзгәрттек. Актлар залы да юк иде. Укучыларның сәләтен күрсәтә алмадык. Хәзер зур сәхнәбез бар, – ди Татьяна Калугина.

Арча районының Түбән Мәтәскә мәктәбендә 500 урынлы яңа мәктәп ачылуын ишетәкчү, аптырап калдык. 11 еллык мәктәпләре бар иде кебек.

– Түбән Мәтәскә ике өлешкә бүленгән бит ул. Берсе – авыл үзе. Икенчесе – Арчадан чыгуга «Арчабаш» микрорайонында. Анда яңа йортлар күп төзелә. Бездә Күпербаш, Арча шәһәренең «Восточный» микрорайоны балалары укый. 300гә якын укучы кабул иттек. Әле тагын 200 балага урын бар. Өч төрле профиль булдырдык. Болар – аграр, инженерлык-техник, инженерлык һәм мәгълүмат технологияләре юнәлешләре, – диде яңа мәктәп директоры Максим Ильясов.

Директор әйтүенчә, яңа мәктәп төзелү Арча шәһәрендәге икенче сменаны бетерергә дә ярдәм итәчәк.

Сәрия МИФТАХОВА

УЛ БИТ АВЫЛ МАЛАЕ

«ВТ» архивыннан

Сагыну

25 августта Туфан ага Миңнуллинга 88 яшь тулырга тиеш иде. Тиеш иде шул, тик хәзер: «Нишлисең, язмыш», – дип күңелне юатырга гына калды. Бөегебез турында хатирәләрне яңарту өчен ел саен аның туган нигезенә – Кама Тамагы районындагы Олы Мәрәтхуҗа авылына барабыз.

Әдипне искә алу мәҗлесе быел төштән соң гына башлана, диделәр. Минем кешегә ияреп йөрисем килмәде, чөнки мондый чараларда, гадәттә, рәсмилек өстенлек итә, эчкерсезлек кими төшә кебек. Һәрхәлдә, миңа шулай тоела. Иртә таңнан берүзем юлга кузгалу да шушы хисләргә бәйле. Әдип нигезендә уйланып утырасым, аның авылдашлары белән очрашып, хәтер яңартасым килде.

Хәтер, димәктән, Туфан аганың бер фикере искә төште әле. Сүзен-сүзгә хәтерләмим.

Ала карга гомерен кеше гомере белән чагыштырган иде ул. Карга ике йөз, өч йөз ел яшәргә мөмкин, ә кеше гомере тартып-сузып йөзгә генә җитә ала. Әмма ул үз гомерен изге эшләр башкарып, матур гамәлләр кылып озайта ала. Ә карга, өч йөз ел яшәсә дә, шул карга булып кала инде, дигәнрәк сүзләр әйткән иде Туфан ага. Ул халык өчен, татар өчен, үзенең туган авылы өчен яшәде.

Олы Мәрәтхуҗаны хәтта дөньяның иң гүзәл шәһәрләренә дә алыштырмый иде ул, «Парижларыгыз үзегезгә булсын!» – дип тә әйткәли иде. Аз гына җай чыккан саен авылына кайтып китәр иде. Авыл халкы аңа бүген әҗерен кайтара, ел саен аның өй каршында чирәмлектә өстәлләр җәеп, туган көн табыны әзерли. Табында – авыл кешеләре үзләре әзерләгән нигмәтләр.

Олы Мәрәтхуҗаның исеме җисеменә туры килеп бетми, олы түгел ул, йортлар саны өч дистә чамасы гына, халык саны да алтмыш тирәсе генә булыр. Әмма яши әле Мәрәтхуҗа. Авыл халкы: «Туфан булмаса, без әллә кайчан бетә идек инде», – дип сөйләнә. Туфан аганың авылда өч йорты бар. Белмим, ни өчен кирәк булгандыр аңа өч йорт? Йортлар саны артсын дип уйлагандыр, бәлки. Бер йортын ул мәктәпкә бүләк итә, икенчесе, бәлки, язучыларга хезмәт итәр дип уйлый. Олы Мәрәтхуҗага килеп ял итәргә, язып утырырга теләүчеләр табылмас, дип өметләнә. Ә үзе яшәгәне – кечкенә генә, бер бүлмәле авыл өе. Башкаларга ияреп, Казанда, Тау Башы бистәсендә дә йорт салдырган иде Туфан абый.

Дусты, фикердәше Разил Вәлиев аңа: «Туфан абый, синең дистәгә якын йортың бар бугай инде, кечкенә агач йортлар салдырганчы ни өчен берәр коттедж гына төзетмисең?» – дигән булган. Туфан абый аңа аптырап бик озак карап торган да ди аннан соң: «Авылча булмый бит ул», – дип әйтеп куйган ди.

Олы Мәрәтхуҗада мине Туфан аганың күршесе Хәмит Рәфыйков каршы алды. Авылда аны «Туфан малае» дип йөртәләр. Үзе югында Туфан абыйның биләмәсенә күз-колак булып торган Хәмит. «Авылга кайтасы булса, миңа шалтыратып куя иде. Бу аның: «Әзерләнеп, көтеп торыгыз», – дигән сүзе түгел иде инде. Без болай да ашарга пешереп, мунча ягып куя идек. Үзенең кайтасын авыл халкы белеп торсын дип уйлагандыр. Чөнки аның янына гозер белән килүчеләр гел күп була иде», – ди Хәмит.

Туфан ага авылдашларына йорт салу өчен төзелеш материаллары табарга да булышкан, чөнки бөтен җирдә сүзе үтә иде, ди Хәмит. Үз авылларына клуб, күрше авылларда мәктәпләр дә салдырткан Туфан ага. Аның Дәүсовет мөнбәрләреннән авыллар, татар язмышы турында өзгәләнеп сөйләүләрен еш искә төшерәм. Сөйләп кенә калмады, бик күп игелекләр дә кылып яшәде ул. Кулыннан килгәнчә, һәркемгә ярдәм итәргә тырышты. Хәмит бер гыйбрәтле хәлне искә төшерде әле. Туфан аганың Казанда, Тау Башы бистәсендә яшәгән вакыты бу. Хәмит аның янына йорт-җирне карашырга, төзү-төзәтү эшләрендә булышырга йөргәли. Беркөнне капкадан бер хатын килеп керә дә: «Туфан Миңнуллин шушы йортта яшиме?» – дип сорый. Хәмит Туфан ага капкасының һәркемгә ачык икәнен белә һәм әлеге хатынны өйгә кертеп җибәрә. Беразвакыт узгач, Туфан ага кунакны озатырга чыга һәм аның артыннан капка ябылгач: «Хәмит, мин бу хатынны бөтенләй белмим, ну шулай да булышырга кирәк», – ди. Бу хәл ни дәрәҗәдә зурлап сөйләрлектер, укучыбыз үзе бәя бирсен. Ә менә Хәмит өчен дә, минем өчен дә бик гыйбрәтле тоелды. Туфан аганың Президент каршындагы Ярлыкау комиссиясендә әгъза булып торган чагы бу. Ә теге хатынның улы ниндидер хаталык белән төрмәгә ябылган булган. Һәм бу хатынның, ярдәм сорап, нәкъ менә Туфан абыйга килүе гаҗәп түгелмени?! Ул Туфан абыйның соңгы инстанция, соңгы өмет санаган. Хәмиттән: «Тегеятен хатынга ярдәм итә алдымы соң?» – дип сорадым. «Тәгаен генә белмим, әмма Туфан абый әйткәнен эшләми кала торган кеше түгел иде», – диде.

Бөтенләй белмәгән кешенең кайгысын үз кайгысы кебек кабул итү алучылар күп түгелдер ул. Гомумән, бар микән әле! Туфан ага һәркемне үзенә тиң күреп сөйләшә белде. Зур-зур дәрәҗәләргә ирешсә дә, гади, чиста күңелле авыл малае булып калды. Шуңа күрә мин Олы Мәрәтхуҗа халкының: «Безнең Туфан!» – дип горурланып әйтүенә, елына ике тапкыр – туган һәм вафат булган көнендә аны бөтен авыл җыелып искә алуына гаҗәпләнмим. Быел да туган көне табыны яшь 87 кеше килгән. Моны Туфан аганың яшь дусты Миңнур Нәбиуллин әйтте, күпме кеше җыелганын махсус санаган. Нибары 60 кеше яшәгән авылдан бит бу! Миңнур әйтүенчә, Туфан аганы искә алу көннәрендә авылдан читкә китеп эшләүчеләр дә кайта икән. Күңелдә шатлык катыш моңсу хисләр иде. «Әгәр Олы Мәрәтхуҗа бетсә, Туфан аганың йортлары буш утырып калыр микән?» – дип куйдым. Миңнур да, Хәмит тә беравыздан: «Авыл бетмәячәк, безнең балалар бар, оныклар үсеп килә, Туфан абый рухын алар күңелендә дә сеңдерергә барабыз», – диделәр. Шөкер, Туфан ага биләмәсе, аның музей йорты капкасы тору өчен ике штат бирелгән. Хәмитнең сеңлесе Гөлнара – музей директоры, хатыны Роза җыештыручы икән. Хәмит моңа шатланып бетә алмый. Гаилә әгъзаларына авылда эш табылуына түгел, Туфан турында халык хәтеренең озак яшәве өчен үзенең гаиләсе, авылдашлары җаваплы икәненә куана ул.

Риман ГЫЙЛЕМХАНОВ

МӘДӘНИЯТ ЯҢАЛЫКЛАРЫ:

ХӘЛ ИТӘСЕ ӨЧ МӘСЬӘЛӘ

Җиде елга сузылган Сәйдәшев музее ремонты, музыкаль театр ачу, Чаллы театры низагы. Журналистлар белән традицион очрашуында Татарстан мәдәният министры Ирада Әюпова әлеге өч темага өстенлек бирде.

Җиде елга сузылган ремонт

– Җиде еллык реставрациядән соң Салих Сәйдәшев музее быел көз ачылачак. Без мемориаль түгел, тере музей ясарга уйладык. Музейда традицион экспозицияләрне, Сәйдәшев исеменә бәйле булган бар нәрсәне күп була. Ләкин алар музей кирәк бөтен гыйлемен генә алып торачак. Бирелә күбрәк аралашу мәйданчыгы булачак. Теләсә кайсы мәдәни киңлекнең төп максаты – аның көчен ачу. Шул исәптән авторларның музыкасын популярлаштыру аша. Кызганыч, кешеләр аларны белеп бетерми. Урамда узып баручыларны туктатып сорасаң, Сәйдәшев турында бик аз кеше генә нәрсәдер әйтә алыр. Халык үз музыкасын һәм геройларын белсен иде.

Музыкаль театр

– Музыкаль-драма театрын хәзергә Камал театры бинасында ачарга ниятлибез. Рөстәм Миңнеханов та безгә музыкаль театр кирәклеге белән килеште. Без бу театр өчен өлгереп җиттек. Профессиональ сәхнәгә менгерерлек әсәрләребез дә бар. Бүген безнең җыелган репертуар күбрәк йә музыка театры ягына, йә драма театры ягына авыша. Әгәр дә без опера турында сөйлибез икән, бу – бик кырыс сәнгать. Бу – математика. Әйтик, Мин «Кара пулат»ны бик яратам, әмма аны опера сәнгате дип әйтеп булмый, чөнки ул аның канупнарына туры килеп бетми. Башта Камал театры өчен яңа бинаны төзеп бетерәсе бар. Фикер алышулар уздырып, тәкъдимнәребезне профессиональ җитәкчесенә җиткерәбез. Әгәр барысы да барып чыга икән, мәдәнияттармагындагы чираттагы хыялым тормышка ашачак.

Чаллы театрындагы низаг

– Мәдәният өлкәсендә иң зур проблема – кадрлар сәясәте. Аның белән беркайчан да канәгать булмаячаклар. Өлкән буын артистлар – театрда озын гомер юлы үткән мэтрлар, бик хөрмәтле кешеләр. Аларның профессиональ осталык дәрәҗәсе, статуслары, титуллары бар... Мин бу очракта беркемне дә акларга җыенмыйм, чөнки кадрлар сәясәтендәге төп проблема кешеләрнең бер-берсе белән очрашып, кешечә сөйләшә алмавы аркасында килеп чыга. Кешеләргә матур итеп, аңлатып әйтергә кирәк. Чишелешне һәрвакыт табарга була. Бу теманың киң җәмәгатьчелеккә чыгуы матур булмады. Югары уку йортын тәмамлаучыларга да каядыр барырга кирәк. Бирелдә ике юл бар. Йә театр өлкәсендә контракт системасын җайларга кирәк, йә Төркиядә эшли торган юл белән китә алабыз. Анда артистларның бердәм реестры бар, кастинг үткәннән соң актерлар төрле театрларга чакырыла. Альтернатив вариант та бар. Олпат артистларга хөрмәт белән караячакбыз, аларны штат расписаниесендә ярты ставкага гына калдырмыйбыз, ә осталык институты булдырабыз. Ләкин монда иң мөһиме – аралашу. Чаллы театры – кечкенә театр. Труппада 50–60 кеше булганда, 15 артист табып була. 30–40 кеше булганда, эшне төзү бик кыен... Олегны (Олег Кинҗәгулов – театрның сәнгать җитәкчесе) да аңларга кирәк, аның спектакльләр чыгарасы бар. Репертуар өчен яшьләр кирәк. Мин аңлыйм, 40–45 яшьтә 32–35 яшьлек кешене уйнарга мөмкин. Ләкин 70 яшьтә 20 яшьлек кызны уйнап булмый.

(Билгеле булганча, Олег Кинҗәгулов театрның өлкән буын артистларын ярты ставкага калдырырга тәкъдим итте. – **Ред.**)

kukmor-rt.ru

Ләйсән САФИНА

«АШЫКТЫҢ ИНДЕ, РАШАТ АБЫЙ!..»

Хушлашу

1 сентябрь татар халкына зур югалту алып килде: шагыйрь, язучы Рашат Миясәр улы Низамиев (Рашат Низами) вафат булды.

Каләмдәшләре әйтүенчә, соңгы сулышына кадәр иҗат иткән ул. Газета-журнал битләрендә аның июль – август айларында басылган әсәрләре, бәлки, укучылар кулына керергә дә өлгермәгәндер әле. Бакыйлыкка да, башкаларны борчымыйча, бакчада ял иткәндә, сиздермичә генә киткән. Хәләле Нәсирә апага: «Бүген яңа бәрәңге пешереп ашыйк әле. Аңарчы мин беразбакчада йөреп керәм», – дигән җирдән генә... Бакча дигәннән, язучы Ләбиб Лерон аның күршесендә генә яшәгән. «Бик елдам, җитез, хәрәкәтчән кеше иде ул. Күрешкән-ниткән чакта, гел каядыр ашыккан чагы булыр иде. Ашыгам, эш күп, малай, дияр иде. Тагы ашыктың инде, Рашат абый. Бу юлы кайталмас якка ашыктың – гел-гел күрешеп булмас якка. Хуш, Рашат абый! Догада булыйк!..» – диде ул.

«Рашат Низами – әдәбияттагы барлык жанрларны да «иярләгән» кеше», – дип яза тәнкыйтьче, әдәбият галиме, Тукай премиясе лауреаты Тәлгать Галиуллин аның хакында. Чыннан да, аның иҗатына зур бәя бирелә. Мәшһүр татар композиторы, беренче татар балеты «Шүрәле»нең авторы Фәрит Яруллин турындагы «Ут һәм җыр» дип исемләнгән роман-хроника өчен

«Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе» исеменә лаек була. Ул – Татарстан Язучылар берлегенең Һади Такташ исемендәге бүләк иясе, Шәйхи Маннур премиясе лауреаты (1992). 16 китап авторы, милли романнар иҗат иткән язучы. 70 яшенә «Уч төбендә яшен» дигән шигырьләр җыентыгы әзерли. Китапларның исемнәре дә үзенә туры килеп тора. Җыр булып яшәде, яшен булып яшьнәде Рашат Низами.

«Ватаным Татарстан» газетасы якыннарының, туганнарының кайгысын уртаклаша.

Рашат Низами 1950 елның 1 мартында Татарстан Республикасының Саба районы Олы Мишә авылында (хәзер Теләче районына керә; Олы Яңавыл исеме белән дә билгеле) колхозчы гаиләсендә туа. Әтисе сугыштан бер кулын югалтып кайткан, амбар мөдире, әнисе хат ташучы булып эшли. Олы Мишә авылындагы башлангыч мәктәптә укыганнан соң, Олы Саурыш сигезьеллык мәктәбендә укуын дәвам итә. 1967 елда Иске Икшермә урта мәктәбен тәмамлый. 1972 елда ул Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегендә укуны белем ала һәм шуннан соң Биектау районы Олы Битаман авылы мәктәбендә укытучы булып эшли. Төрле вакытта «Татарстан яшьләре» газетасында (1976–1981 елларда), «Ялкын» (1981–1983 елларда), «Казан утлары» журналларында эшли. 1997–2006 елларда «Идел» яшьләр журналының баш мөхәррире була. Язып калдырган васыяте буенча, 2 сентябрьдә хәләл җефетенең туган ягы – Әтнә районы Бәрәзә авылында җирләнә.

> «Оныкларга иман нуры салсак, Туган телне яңгырата алсак, Үлемсезлек михрабында калсак – шулдыр татарлык көзгесе!»
>
> «Тел – тормышыбызны әйдәп-бизәп торган могҗиза, кодрәтле бөек сер. Туган телне саклау, кадерли белү, аны түкми-чәчми буыннан-буынга тапшыра килү – бик тә әһәмиятле бурыч. Телең бетсә, илең дә, милләтең дә юкка чыга, башка халыклар тарафыннан йотыла». (Рашат НИЗАМИ)

Язучы сүзе

Марат КӘБИРОВ

Рейтинглар турында

Төрле китаплар һәм язучылар рейтингы төзү гадәте яши. Сезнең дә очратканыгыз бардыр: «иң күп укылган китаплар», «иң күп сатылган», «иң популяр язучылар» һ.б. Бу соңгы елларда бездә дә кулланыла башлады. Һәм укучыларның миңа сораулары арасында да шуңа бәйлеләре күбәеп китте: «Мондый рейтингларга карашыгыз ничек?»

Күптән түгел Татарстан Милли китапханәсе төзегән популяр язучылар рейтингына да бәйледер бу, бәлки. Анда хәтта татарның бик популяр классиклары да артта калган, ә алдагылары – бик үк танылмаган яңа исемнәр. Шушы хәл кайберәүләрнең әчен пошыра, «Неужели бу яңа авторлар классиклардан да популяррак икән?» – дип уйларга мәҗбүр итә бугай.

Рейтингларга минем мөнәсәбәтем әйбәт. Алар әдәбият белән кызыксынучыларның игътибарын җәлеп итә, китаплар һәм язучылар турында фикер алышырга сәбәп бирә. Шуңа аны нәшриятлар да, китап кибетләре дә киң куллана. Тик «иң-иң»нәр исемлеген кире каккысыз хакыйкать, ягъни чын дөреслек дип кабул итәргә ярамый.

Кибетләрдә, әйтик, «бестселлерлар» исемлеге тора икән, бу әле аларның чынлап та иң күп сатылганлыгын аңлатмый. Бу кибетчеләрнең нәкъ менә шушы китапларны сатарга теләвен, аларга игътибар җәлеп итәргә тырышуын аңлата. Монысы да начар түгел, димәк, алар кемнәрәдер ошаган, башкаларга да укытырга телиләр. Әлбәттә, бүтән сәбәпләре дә булырга мөмкин, әйтик, югарыдан шулай кушканнар, автор үзе бик үтенеп сораган, бу китаптан тизрәк котылырга кирәк, яки аңа бәйле реклама кампаниясе бара, яки ул бүгенге иҗтимагый хәлләр белән авазаш... Тик андый нәрсәләр исемлектәге бөтен китапларга кагыла алмый, бер-икесе генә шундый булырга мөмкин. Югыйсә аңа беркем дә ышанмаячак. Димәк, мондый исемлеккә кергән китаплар игътибарга лаек, һәм алар укучыга юнәлеш бирә ала.

Бик популяр булып та, рейтингларга керми калганнары да була. Моның да сәбәпләре төрлечә: илдәге вазгыять, исемлек төзүчеләрнең эчке һәм тышкы сәясәте, зәвыгы, авторларның теләге һ.б. Әйтик, күптән түгел генә Мәскәү язучыларының бер өлеше исемнәре чит ил агентлары арасына кертелгән авторларның китаплары һәр рейтингның башында торуына кискен каршы чыкты. Моңа аңлатма бирү кирәкмидер. Яки берәр нәшрият шундыйрак рейтинг төзи икән, ул хәтта аны бик объектив дип игълан итсә дә, үзе чыгарган китапларны күбрәк кертергә тырыша. Чөнки аның укучы игътибарын нәкъ шуларга юнәлтәсе килә. Исемлекне әдәбият галиме төзи икән, ул аларны үз зәвыгыннан чыгып бәяли. Ул өйрәнгән, бөтен нечкәлекләренә кадәр белгән, студентлары белән бергәләп тикшерергә омтылган әсәрләр (нигездә, классик әсәрләр) тупланмасы килеп чыга. Шул рәвешле, бер генә рейтинг та объектив була алмый. Популяр китаплар яки авторлар исемлеген караганда, аларны кем төзүенә һәм авторларның кайсы даирәдә популяр булуына игътибар итәргә кирәк.

Китапханәләр төзегән рейтинг, мәсәлән, анда йөрүчеләр күбрәк укыган китапларга нигезләнеп эшләнә. Төзүчеләр гадел булган очракта да бу исемлек чын дөреслекне чагылдыра алмый. Беренчедән, китапханәнең үзенә дә йөрүчеләр сирәк. Йөргәннәре тарихка бәйле әсәрләрне, бик күп еллар элек чыккан китапларны эзләп килә. Болар – студентлар, галимнәр яки әдәбиятка бәйле һөнәр ияләре. Шул уңайдан күзенә бәрелебрәк торган яки китапханәче тәкъдим иткән яңа китапны әләктереп китәргә мөмкиннәр. Укырлык булса, укый инде ул аны, укырлык булмаса, кире илтеп бирә. Ә китап авторы хисабына бер балл языла – бер кеше укыды...

Хәзер Татарстан Милли китапханәсе төзегән исемлеккә якынрак килик. Классик язучыларның арттарак калуы гайре табигый хәл түгел. Әдәбият сөючеләрнең күбесенә таныш бит инде ул әсәрләр. Күпләрнең шәхси китапханәсендә дә бардыр. Мин, мәсәлән, торым-торымга актарып карарга кирәк дип тапкан китапларны кул астында тотарга тырышам. Китапханәгә керсәм, классиклар китабын күтәреп кайтмыйм, исеме телгә кергән яки бөтенләй яңа күренгән хәзерге авторны алам.

Әгәр «иң-иң»нәр исемлегендә сез бик яраткан һәм популяр дип уйлаган автор юк икән, моңа борчылырга ярамый. Бу аңа игътибар кимүен яки түбән тәгәрәвен аңлатмый. Алай булса да гаҗәп түгел. Хәтта кояш та бер урында гына тормый, ул я түбәнлектә була, я күренми тора. Аңа карап кына без кояшны юкка чыккан я түбәнлеккә төшкән дип уйламыйбыз бит. Ул һәрвакыт үзе булып кала.

Яңа исемнәрнең беренчелектә булуына гаҗәпләнергә яки борчылырга кирәкми. Беренчедән, монда авторларның бер гаебе дә юк, алар мондый исемлекне үзләре төземәгән. Икенчедән, бөтен нәрсә үзгәрештә һәм иң яраткан язучыларыбызны да уздырырлык яңа авторлар килүчәк. Шулай булырга тиеш. Бәлки бүген сез беренчелекне күпсенгән каләм ияләре иртәгә яраткан язучыгызга әверелер. Әдәбиятка алар юкка гына килмәгән бит инде. Һәм мондый исемлеккә дә бер сәбәпсез генә кертелмәгән.

Һәр язучының һәр уңышы өчен сөенергә кирәк, чөнки бу – әдәбиятның да уңышы.


Илдар Мөхәммәтҗанов

УКУЧЫ СҮЗЕ

Һәйкәл кайчан була?

Кулымда – татар халкының, төркиләрнең бөек җырчысы Илһам Шакировның юбилеена багышланган «Илһам» исемле 125 битле кечкенә генә китап. Аны күренекле шагыйрь Разил Вәлиев төзегән, 1995 елда нәшер ителгән. Кечкенә булса да, төш кенә ул. Эчтәлеге бик бай, тарихи яктан әһәмиятле мәгълүмат чыганагы. Анда Илһамның тиңдәшсез моңлы җырларына мөкиббән инсаннарның хатирәләре тупланган. Язмаларда җырчының титаник иҗатына соклану, горурлану, ихлас мәдхия белдерелгән.

Беренче биттәге кереш сүзендә Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов җырчыны болай дип зурлый: «Аллаһ биргән талант, тиңдәшсез тавыш Илһам Шакировка татар моңын һәм татар музыкасын бөтен дөньяга данлыклы итәргә мөмкинлек бирде. Илһам бөек моңы белән татарларны бер гаиләгә җыя. Без аның исемен мәңгеләштерергә бурычлы». Беренче Президентыбыз Минтимер Шәймиев: «Илһам Шакиров татар халкына иң якын зат иде. «Моң»ның русчага тәрҗемәсе булмаса, «Моң ул – Илһам!» дип әйтик», – дигән теләкләрен җиткерә. Татарстан Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин: «Илһам кебек талантыбыз булу – барыбыз өчен дә горурлык ул», – дип яза. Җырчы үзенең ярты гасыр дәвамындагы намуслы, шанлы хезмәтенә: «Бөтен иҗат гомерем татарны татар итеп яшәтүгә, аның милли тойгыларын уятуга багышлап үтте», – дип нәтиҗә ясый.

Тик сүз башым һәйкәл турында иде бит. Шөкер, мәркәзебез Казанда Габдулла Тукай, Салих Сәйдәшевләрнең мәгърур һәйкәлләре басып тора. Истәлекле даталарда милләтпәрвәр затлар, язучылар, мәдәният, сәнгать оешмалары хезмәткәрләре һәйкәлләргә чәчәк куялар, чыгыш ясыйлар. Шушы ике бөек зат тирәсендә өченче шәхесебезгә – Илһам Шакировка һәйкәл куелса, зыялыларыбыз атаган бөекләр ансамбле тулыланып, җөмһүриятебез тарихында абруйлы урын биләр иде. Бу изге гамәл халкыбыз күңеленә дә хуш килер, мәшһүр затларыбыз белән горурлану хисләре тагын да ныгыр иде.

Мине Илһам Шакиров иҗатына, моңлы җырларына мөкиббән кеше буларак, бары шул сорау бимазалый: Казан каласы үзәгендә бөек җырчыга һәйкәл куелачакмы? Куелса, бу тарихи вакыйга татарларны кайчан куандырыр икән? Борчылуга җитди сәбәпләр бар. Җырчының вафатыннан соң инде биш ел үтте, тууына 90 ел (2025 елда) якынлаша, ә аңа һәйкәл кую юнәлешендә бернинди хәрәкәт күзәтелми. Скульпторлар өчен бәйге әле дә игълан ителмәгән. Һәйкәлне урнаштыру урыны да билгесез. Бу мәсьәлә ничек хәл ителә, берәр план бармы икән?

Марс ГАИТОВ

Илдар Мөхәммәтҗанов

Өч көн ашамасаң – өч капчык

Миңа – 83 яшь. Шөкер, газета-журналлар да, китаплар да укыйм әле. Күптән түгел Фирдәвес Хуҗинның «Суслонгер» китабы кулыма керде. Онысым Казаннан алып кайтып бирде. Шуны укыгач, хәтер йомгагым сүтелеп китте. Сезнең газета аша авторга зур рәхмәтләремне җиткерергә иде исәбем.

Минем әтием Гаяз да шул лагерьда җәфаланган. Әнием Миннехәят өч авылдашы – Кәтифә Сәхапова, Миннехәят Низамова, Зәйтүнә Сәйфетдинова белән җәяүләп ирләренә ашарга илтә барганнар. Андагы хәлләрне күреп кайткач, елый-елый сөйләделәр.

Әтиебез, шөкер, 7 елдан соң исән кайтты. Ул сөйләгәннәр дә хәтердә калган. «Ашарга юк, кайвакыт карабодай чүбе китереп салалар. Кайберәүләр ашый. Ә кайсыларының тамагыннан үтми иде. Беркөнне өшегән кызыл чөгендер китереп ыргыттылар. Ачтан үләсе килми бит, шуны барыбыз да ашадык инде. Икенче көнне эчебез китә башлады. Шундагы бер зур кеше әйтүенчә, врач килгән, өч көн ашамаска кушкан икән. Өч көнлек ризыкны өч капчыкка алыштырдым. Берсен баш астына салдым, икенчесен астыма җәйдем, өченчесе белән ябынып яттым. Шулай итеп исән калдым. Бер көн ашамасаң, бер капчык бирәләр иде. Без анда урман кистек тә җилкә белән күтәреп ташыдык, җир казыдык, таш ташыдык. Берничек тә сугышка әзерләмәделәр», – дия иде.

Тикшергәч, гаепләләр атып үтерелгән, диелгән китапта. Солдатларны җәфалаган кебек ул зәхмәтләрне дә ач тотарга иде шул землянкаларда. Әтием, безне сөендереп, озак яшәде: 96 яшендә вафат булды. Китапның тышлыгына карыйм да, гел әтием утырып тора төсле. Ул да дини кеше иде.

Редакция хезмәткәрләренә дә бик зур рәхмәтләремне җиткерәм. Безне шатландырып яшисез. Газетаны үзебезне белә-белгәннән гаиләбез белән бик яратып укыйбыз.

Галия КАМАЛОВА.
Алексеевск, Кыр Шонталысы

Илдар Мөхәммәтҗанов

Туган авылым

Бик еш кайтып булмый авылларга,
Газиз әткәй-әнкәй янына.
Инде читтә яшәп өйрәнсәк тә,
Күңел һаман шунда ашкына.

Төшләремә керә туган авылым!
Туган йортым! Туган нигезем!
Бар күңелем белән сизәм сыман
Туган якның йөрәк тибешен.

Авылымның салкын чишмәләрен
Төштә күреп, сусап уянам.
Күз алдымда газиз балачагым!
Тиле яшьлегемне сагынам.

Авылдашлар! Бергә үскән дуслар!
Сагынамын хәзер барсын да!
Рәхмәтлемен биргән илһамыңа,
Туган авылым, синең каршыңда!

Румия САДРЕТДИНОВА

Сөенечле хәл

Татарларда, кайда яшәүләренә дә карамастан, бердәмлек хисе ныгыганнан-ныгый. Ил күләмендә уртак чаралар арта бара. Әйтик, татарча диктантны Татарстанда гына түгел, хәтта Россиядә генә дә түгел, Европада да, Америкада да, гомумән, барлык континентларда да уңышлы гына язалар. Ә бу телебезне ныгыту, аның мәңгелегенә юл ачу булып тора.

Киләчәгебезне кайгырту беренче урынга чыгып бара. Моның бер якты күренешен Чуашстанның Тукай авылында күрергә була. Монда 5–6 яшьтән балаларны намаз укырга өйрәтәләр. Балаларны мөстәкыйль тормышка әзерләү яшәү рәвешенә әверелгән. Гомумән, бу авылда тормыш кайный. Шәһәрдән күчеп килүчеләрнең саны арта тора. Пенза өлкәсенең 11 мәчетле Урта Әләзән, Татарстанның Шәле, Киргәч, Керкәле кебек авылларында да кешеләрнең бер-берсенә ышаныч белән сугарылган тормыш кайный. Балаларга милли һәм дини тәрбия бирү, аларга телебезне ныклап сеңдерү Себер һәм Уралда да – яшәү рәвеше. Татарларның ярдәмләшеп яшәүләре гадәти хәлгә әверелеп бара. Бу бик сөенечле.

Индүс ТАҺИРОВ

СЕЗДӘ НИЧЕК?

Газетаның 25 августта чыккан җомга санында соңгы биттә сирәк кулланылучы сүзләр бирелгән иде. Шунда «алчак» сүзенә күзем төште. «Оятсыз» дигәнне аңлата дип язылган. Тик менә безнең якта ул сүз эчкерсез, күңелле, башкалар белән тиз аралаша, эчендәге тышында булган кешеләр турында әйтелә. Кызык булып китте. Башка якларда ничек икән ул? Бу сүзне кулланган кешеләр шул хакта язсыннар иде.

Фәргать РӘХИМОВ.
Арча, Түбән Аты

Бәхет иңгән җирем

Казандагы «Апас» якташлык җәмгыяте оешуга – 30 ел. Аның беренче президенты, гипс чыгару карьеры генераль директоры Шәүкәт Кәлимуллин иде. Ул, якташларыбызны барлап, биниһая зур эш башлап җибәрде. Бер-берең белән аралашу, очрашу кичәләре, зур концерт программалары гамәлгә ашырылды. Ярдәмләшеп яшәү якташларыбызның яшәү нормасына әверелде.

Аннары эстафета спорт мастеры, Татарстан Республикасының спорт комитеты рәисе урынбасары Мансур Мифтаховка күчте. Ул чактагы Апас районы башлыгы Азат Хәнифәтуллин белән бергәләп эшләү нәтиҗәсен озак көттермәде, апаслыларга танылу килде. Хәтта башка районнар да, безнең очрашу кичәләренә махсус килеп, оештыру алымнарына өйрәнделәр. Аларда да җәмгыятьләр оеша башлады.

Хәлим Гайнуллин исә – өченче президент. «Хокук һәм хәят» журналының баш мөхәррире. Танылган каләм остасы бик күп апаслыларны эзләп тапты. Әтиәнисе Апас төбәгеннән булган экс-прокурор Кафил Әмиров, күпсанлы фән эшлеклеләре, язучы-журналистлар, докторлар, педагоглар, гомумән, төрле төр профессия вәкилләре бар иде араларында. Хәтта илебезнең ерак кыйтгаларында яшәүче якташларыбыз да, эшмәкәрләр дә тартылды бу җәмгыятькә. Апас Сабан туе һәркем өчен зур бәйрәмгә әверелде. Якташларны бүләкләү тантанасы әле дә хәтердә яңара. Хәлим әфәнде үзе Кызыл Тау авылыннан. Галим Мөхәммәт Гайнуллин да шушы ук авылдан. Аларның бары фамилияләре генә аваздаш. Хәлим Гайнуллин тырышлыгы белән Мөхәммәт Гайнуллин исемендәге премия булдырылды. Һәм Апас районы мәктәпләренең иң яхшы укучыларына тапшырылды.

Аннары җәмгыятьне Апас башлыгы Азат Хәнифәтуллин җитәкләде. Ул һәркемне аталарча кайгыртты һәм кайгырта. Шигъри җанлы Азат әфәнде «Айсалан аланнары» дигән җыр да иҗат итте. Әлеге җыр апаслылар күңелендә районыбызның гимны кебек яңгыраш тапты. Очрашу кичәләренә эшкуар Әсгать Галимҗановның килүе аеруча истә калган. Андый шәхесләр, Беренче Президентыбыз Минтимер Шәрипович Шәймиев әйткәнчә, алтын бәрабәренә тиң. Азат Сафинович янәшәсендә гадәттән тыш хәлләр министры Рафис Хәбибуллин, фәннәр докторы Рәшит Исламшин, Татарстан Премьер-министры урынбасары Шамил Гафаров, «Татхимия» берләшмәсе генераль директоры Наил Гобәйдуллин кебек шәхесләр булды. Азат Сафинович һәркем йөрәгенә кирәкле ачкыч таба белде. Халык җырчылары Илсур Сафин, Фердинант Сәлахов та – безнең горурлыгыбыз. Алар – җырлы-моңлы кичәләрнең бизәге. Язучы, танылган актер Әмир Камалиев (Аманулла), драматург Хәбир Ибраһимов та гел янәшәдә булды.

Хәзер якташлар җәмгыятен Дәүләт Думасы депутаты Марат Нуриев җитәкли. Танылган, эшлекле җитәкче аңа кадәр дә һәр очрашуның үзәгендә кайнады. Якташларыбыз еш кына тормыш-көнкүрешен зәвыклырак итү хакында фикер алышалар. Зурлап Корбан ашлары уздыралар. Апас районы хакимият башлыгы Айрат Җиһаншин белән даими аралашып, килеп туган проблемаларны уртага салып хәл итәләр.

Әле бу араларда җәмгыять җитәкчесе ярдәмчесе Наил Галиуллин янә безне үзенә чакырып алды. «Гасырлар сагындагы манаралар» китабын бүләк итте. Аны ачканда, хөрмәтле якташыбыз, күренекле дин әһеле Рамил хәзрәт Юнысовның аһәңле тавышын ишеткәндәй булдык. Килүчеләр арасында Хәлим Гайнуллинның хәләл җефете, югары категорияле укытучы, Путин гранты иясе Фәнисә ханым, «Күчтәнәч» тапшыруының Дәү әнисе Әлфинур Хисамова бар иде. Шулай ук гомере буе кеше сәламәтлеге сагында торган, Россия Сәламәтлек саклау министрлыгының «Почет билгесе» ордены белән бүләкләнгән Рузия Юсупова да якташлар адресына җылы сүзләрен әйтте.

Алсу БИКБАЕВА

БЕЗДӘ БҮГЕН АЛТЫН ТУЙ

Әнием Язилә белән әтием Сәгыйть Галиевларның гаилә корып яши башлауларына – 50 ел. Икесе дә Алексеевск районы Кыр Шонталысы авылында туып-үскәннәр. Бүген алар – кадерле әти-әни, яратып туя алмаслык әби-бабай.

Әтием армия сафларында хезмәт итеп кайта да туган авылында эшли башлый. Бу вакытта әнием, яңа гына мәктәпне тәмамлап, зур хыяллар белән канатланып, шәһәргә китеп укырга керергә теләп йөри. Мәктәптә ул иң алдынгы укучыларның берсе була. Укытучылар да, аның югары уку йортына кереп, дипломлы һөнәр иясе булуына зур өметләр баглый. Ләкин мәхәббәт үз эшен эшли. Яшьләр гаилә коруны хуп күрәләр.

Гаилә учагын кабызып җибәрер өчен күп көч куярга туры килә аларга. Уңган, баскан җирендә ут чыгара торган тырыш әбиебез аларга терәк була. Әтием дә, әнием дә укырга хыяллана. Бу теләк аларны Буа ветеринария техникумына илтә. Шул ук вакытта алар икесе дә бик шаян, шук, тормышка үлеп гашыйк кешеләр була. Бәйрәмнәрдә, Сабан туйларында, туйларда әтием кебек оста биюче булмый. Бию ярышларында, тирләп-пешеп, көйнең ахырына кадәр биеп, җиңү яулый торган була ул.

Әтиебез озак еллар колхозда мал табибы булып эшләде. Колхоз терлегең генә карап калмый, ярдәм сорап килгән авыл кешеләренең үтенечен дә кире какмый ул. Хәзер дә алган белемен файдаланып, авыл халкының рәхмәтен ишетеп яши. Әнием колхозда иң алдынгы сыер савучыларның берсе иде. Без, кызлары, аның янына еш бардык. Бу хезмәтнең хатын-кыз өчен никадәр авыр булганын үз күзләребез белән күреп үстек. Ул вакытларда 25–30ар баш сыерны кул белән савып, саламын, печәнен, онын үзләре ташыйлар иде. Әниемнең фотосын мактау такталарында да бик еш күрдек, мактау грамоталары белән дә бүләкләнде ул. Хезмәтенә тугры, сүзгә оста, белемгә омтылышы булганга, аны коммунистлар сафына да кабул итәләр. Аннары ул районда иң алдынгы саналган «Вахитов» колхозы фермасына мөдир итеп сайлана. Анда да гадел, тырыш, кешелекле икәнен күрсәтә.

Тәгәрәп барган тормыш, матур хыяллар, киләчәккә булган якты өметләр бердәнбер көнне чәлпәрәмә килә. Бу безнең өчен иң куркыныч көн булгандыр, мөгаен. 1994 елның зәмһәрир салкын гыйнвар аенда якын кешеләребез юл һәлакәтенә очрый. Шул көнне әтием бер аягын югалта, әнием хастаханәгә эләгә. Озак вакытлар тәндәге яраларны гына түгел, күңел җәрәхәтләрен төзәтергә туры килә аларга. Бу вакытта апабыз Гөлчәчәк – югары уку йортында, мин энем Самат белән мәктәптә укый идек, ә кечкенә сеңлебез Гөлгенәгә бары 2 яшь иде.

Сәхнәләрдә ут чыгарып биюче әтиемә бу фаҗиганең ачысы күбрәк сизелгәндер, билгеле. Ләкин янәшәсендә яратып, ярты сүздән аңлап торучы әнием булганга, ул беркайчан да төшенкелеккә бирелмәде.

Бүген миннән: «Кемнән үрнәк алып яшисең?» – дип сорасалар, мин ике дә уйламыйча, әтием белән әниемнән, дияр идем. Заманалар үзгәреп, колхозлар юкка чыккач, һәр гаилә җан асрарга, көн итәргә, тормыш алып барырга тырышты. Кемдер бу елларда тормыш батгаклыгында югалып калды, кемдер, үзендә көч табып, алга омтылды. Әтием белән әнием беркайчан да, бездән булмый, дип мескенләнеп өйдә ятмадылар. Үз эшләрен башлап, эшмәкәрлек белән шөгыльләнә башладылар. Беренчедән,

Гаилә архивыннан

бу әти-әниемә үзләрен сынарга бер адым да иде. Һәм алар бу авырлыкларны җиңеп чыктылар. Матур йорт булдырдылар, бакча тулы җиләк-җимеш, яшелчә үстерделәр, терлек-туар, кош-корт үрчеттеләр. Шулар белән юанып, барлыкка куанып, матурлыкка сөенеп яшәгәндә генә яшәүнең кадерен беләсең икән ул.

Бүген әтиемнең эшен энебез Самат дәвам итә. Без, өч кыз, югары белем алып, үз хезмәт җимешләребезнең тәмен белеп яшибез. Барыбыз да әти-әни йортына, канатланып, рәхәтләнеп киләбез. Кайчан барма, әниемнең бәлешләре, коймаклары пешкән булыр, ә әтиебез һәрвакытта елмаеп, куанып каршы алыр.

2017 елдан бирле әнием авылда мөгаллимә, остабикә булып тора, халыкны, үсеп килүче буынны дин, әхлак ягыннан тәрбияләүгә зур өлеш кертә. Мәчеттә хатын-кызларны дин нигезләренә һәм гарәп теленә өйрәтә. «Кешеләргә матди байлык кына түгел, рухи байлык та кирәк», – ди ул. Күптән түгел Казан «Мөхәммәдия» мәдрәсәсен әйбәт кенә тәмамлап, диплом алып чыкты. Бу уңышка ул бары тик әтиебезнең ярдәме, хуплап торуы, булышуы белән генә иреште. «Беркайчан да укырга, белем алырга соң түгел», – дип әйтергә ярата әнием.

Бүген аларның барлыгына сөенеп яшәүче дүрт баласы, ун оныгы бар. Өй ишекләре күрше-күләнгә, туган-тумачага, дус-ишләргә һәрвакыт ачык.

Мин Ходайдан аларга бары тик саулык, сәламәтлек, күңел тынычлыгы гына сорыйм. Яшәгән һәр көннәре бәйрәм кебек булсын иде. Туасы таңнары шатлык, тынычлык белән атсын да көтелмәгән җирләрдән куанычлар гына бүләк итсен. Озак еллар шулай матур пар булып, бер-берсен аңлап, ярдәмләшеп яшәсеннәр иде.

Гөлсирин КАМАЛОВА.
Алексеевск, Кыр Шонталысы



ХУШ, НАИЛ АБЫЙ!

Казанда яшәүче Наил Зиннәтуллин «Ватаным Татарстан»ның бик якын дусты иде. Гомере буе газетаны алдырды ул. Почта аша түгел, үзе безгә килеп алыр иде. Бик ипле, кешелекле иде. Кайчагында газета бирә торган бүлмә ишеге бикле булса, сабыр гына ишек төбендә көтәр иде. Әллә каян исәнләшеп, хәлләребезне сорар иде. Соңгы арада алар редакциягә хатыны Юлия ханым белән бергәләп килделәр. Аларга сокланмый мөмкин түгел иде. Бер-берсенә тугры бу пар турында газета битләренә дә язган идек. Инде менә хәзер үткән заманда сөйләшергә туры килә. 27 август көнне Наил абыебыз бакыйлыкка күчкән. Бу хәбәрне ишетү җиңел булмады. Үз кешебез идең бит, Наил абый. Урының оҗмахта булсын, гаиләңә сабырлык телибез.

КАЙГЫ УРТАКЛАШУ

ЗИННӘТУЛЛИН Наил Зиннәтулла улы
вафат булу сәбәпле, тормыш иптәше Юлия, балалары Рөстәм, Эльза туганнарының авыр кайгысын уртаклашалар.

КОТЛЫЙБЫЗ!

Төбәкара хезмәттәшлекне ныгытудагы казанышлары һәм Зәй муниципаль районының социаль-икътисадый үсешенә зур өлеш кертүе өчен Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы башлыгы **Кәримов** Разиф Гали улы **«Дуслык» ордены** белән бүләкләнде.

***

Химия өлкәсендә фундаменталь тикшеренүләрне үстерүдәге мөһим казанышлары, нәтиҗәле фәнни эшчәнлеге һәм югары квалификацияле белгечләр әзерләүгә өлеш кертүе өчен «Россия Фәннәр академиясенең Казан фәнни үзәге» федераль тикшерену үзәге» федераль дәүләт бюджет фәнни учреждениесенең аерымланган структур бүлекчәсе – А.Е. Арбузов исемендәге Органик һәм физик химия институты җитәкчесе **Карасик** Андрей Анатольевич; Татарстан Республикасы мәнфәгатьләрендә күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен хезмәт ветераны **Сөләйманова** Нурсинә Гыйлаҗ кызы; татар мәдәниятен саклауга һәм музыка сәнгатен үстерүгә мөһим өлеш кертүе, күпьеллык иҗади эшчәнлеге өчен вокалчы артист (солист) **Сөнгатуллин** Мирзәет Миншаһит улы; халык сәламәтлеген саклау эшенә мөһим өлеш кертүе һәм күпьеллык намуслы хезмәте өчен «Чүпрәле үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе табиб-хирургы **Шигабутдинов** Илмас Илял улы **«Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен» ордены медале** белән бүләкләнде.

***

Халык сәламәтлеген саклау эшендәге казанышлары һәм күпьеллык намуслы хезмәте өчен Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының «Казан дәүләт медицина университеты» федераль дәүләт бюджет югары белем бирү мәгариф учреждениесенең белгечләрнең квалификациясен күтәрү һәм һөнәри яктан яңадан әзерләү факультеты неврология һәм нейрохирургия кафедрасы мөдире **Данилов** Валерий Иванович; законлылыкны һәм хокук тәртибен ныгытудагы, гражданнарның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклаудагы казанышлары өчен Татарстан Республикасы прокуратурасының федераль куркынычсызлык, милләтара мөнәсәбәтләр, экстремистлыкка һәм террорчылыкка каршы көрәшү турында законнар үтәлешенә күзәтчелек бүлеге башлыгы **Исмәгыйлев** Илдар Камил улы; һөнәри эшчәнлектәге югары казанышларга ирешүе һәм күпьеллык намуслы хезмәте өчен «СОЗИДАНИЕ» ИДАРӘЧЕ ШИРКӘТЕ» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте генераль директоры **Мифтахов** Марат Әнәс улы; конкурентлыкны үстерү өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыруга зур өлеш кертүе һәм күпьеллык намуслы хезмәте өчен Монополиягә каршы федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы буенча идарәсе җитәкчесе урынбасары **Розенталь** Андрей Николаевич; мәдәниятне һәм сәнгатьне үстерүдәге казанышлары һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен «Мисс Татарстан» Татарстан республика иҗтимагый оешмасы президенты, «МТ моделс» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте генераль директоры **Сахарова** Изольда Генриевна; республиканың нефть сәнәгатен үстерүгә зур өлеш кертүе һәм күпьеллык намуслы хезмәте өчен В.Д. Шашин исемендәге «Татнефть» гавами акционер җәмгыятенең «Татнефть-Добыча» структур бүлекчәсе «Лениногорскнефть» нефть һәм газ чыгару идарәсе производствога хезмәт күрсәтү цехы башлыгы **Фәрхетдинов** Альберт Хәмзә улы; театр сәнгатен үстерүгә зур өлеш кертүләре һәм күпьеллык нәтиҗәле иҗади эшчәнлекләре өчен «К. Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры» дәүләт бюджет учреждениесе драма артисты **Гарәпшина** Гүзәл Мөдәррис кызы, «Галиәсгар Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры» дәүләт бюджет учреждениесе драма артисты **Зарипова** Зөлфирә Сафа кызы, «Казан дәүләт яшь тамашачы театры» дәүләт бюджет учреждениесе артисты **Царьков** Евгений Степанович, «А.В. Баталов исемендәге Бөгелмә дәүләт рус драма театры» Татарстан Республикасы дәүләт автоном мәдәният учреждениесе драма артисты **Чистякова** Галина Ивановна; республикада музей эшен үстерүгә зур өлеш кертүләре һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәтләре өчен «Татарстан Республикасы Милли музее» дәүләт бюджет мәдәният учреждениесе филиалы – А.М. Горький һәм Ф.И. Шаляпин музее өлкән фәнни хезмәткәре **Мирзина** Флюра Фәрит кызы, «Татарстан Республикасы Милли музее» дәүләт бюджет мәдәният учреждениесенең әйбер чыганаклар бүлеге мөдире **Новикова** Марина Петровна **Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале** белән бүләкләнде.

***

Татарстан Республикасының социаль-икътисадый потенциалын ныгытуга зур өлеш кертүе һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен **Камалов** Рамил Такый улы **«Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы төзелүгә 100 ел» медале** белән бүләкләнде.

***

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсе Ветеринария иминлеге һәм дәүләт күзәтчелеге Түбән Кама территориаль бүлеге консультанты **Сөләйманов** Әнәс Салихҗан улына **«Татарстан Республикасының атказанган ветеринария табибы»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

«Татарстан Республикасы Милли музее» дәүләт бюджет мәдәният учреждениесе филиалы – А.М. Горький һәм Ф.И. Шаляпин музее мөдире **Гаврилова** Марианна Фридриховнага, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының «Район Мәдәният йорты» муниципаль бюджет учреждениесенең халык курчак театры режиссеры **Гасимов** Инсаф Мәсләви улына, Мөслим балалар сәнгать мәктәбе» муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учреждениесе укытучысы **Йосыпова** Гөлназ Моряк кызына, «Татарстан Республикасы мәдәният өлкәсендә инновацияләр кертү һәм традицияләрне саклау ресурс үзәге» дәүләт бюджет учреждениесенең традицион халык хореографиясе буенча эксперты **Яфарова** Лилия Гаделша кызына, «Биектау үзәкләштерелгән китапханә системасы» муниципаль бюджет учреждениесе Үзәк китапханәсенең хезмәт күрсәтү бүлеге мөдире **Князева** Ирина Эмарзяновнага, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының «Кукмара балалар музыка мәктәбе» өстәмә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе укытучысы **Мамкина** Динара Рәфкать кызына, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының «Район Мәдәният йорты» муниципаль бюджет учреждениесенең структур бүлекчәсе – Нырья авылы мәдәният йорты директоры **Семенов** Бориска **«Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

«БИГЕШ» АЭРОПОРТЫ» акционер җәмгыятенең инженерлык-авиация хезмәте һава судноларына җирдә хезмәт күрсәтү буенча белгече **Левашов** Максим Петровичка, «БИГЕШ» АЭРОПОРТЫ» акционер җәмгыяте генераль директоры **Парфененко** Андрей Петровичка **«Татарстан Республикасының атказанган транспорт хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Олимп» спорт мәктәбе» муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учреждениесенең чаңгы ярышлары буенча тренеры-укытучысы **Гыйздетдинов** Таһир Вагыйзь улына, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «3 номерлы комплексны спорт мәктәбе» муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учреждениесе директоры **Сафиуллин** Азат Зәкиулла улына, Татарстан Республикасы «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең «Трамплиннан чаңгыда сикерү һәм ике төрдәге чаңгы ярышлары буенча А.В. Звягинцев исемендәге олимпия резервы спорт мәктәбе» муниципаль бюджет учреждениесе тренеры **Щербаков** Николай Валентиновичка **«Татарстан Республикасының атказанган физик культура хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

«Түбән Каманың техник углерод заводы» акционер җәмгыяте хезмәткәрләре: техник углерод җитештерү цехының техник углерод алу аппаратчысы **Биктимеров** Равил Зиннур улына, техник углерод җитештерү цехының техник углерод производствосы чималны бушату һәм әзерләү участогының чималны әзерләү, ярымфабрикатларны һәм продукцияне төяп җибәрү аппаратчысы **Нургалиев** Рәшит Нуретдин улына **«Татарстан Республикасының атказанган химигы»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

«ТАНЕКО» акционер җәмгыяте хезмәткәрләре: нефть эшкәртү заводының эшләтеп җибәрү-көйләү эшләре төркеме (күкертле нефть продуктларын гидрирлау (гидродеароматизация) җайланмасын эшләтеп җибәрү буенча) инженер-технологы **Гайнетдинов** Ринат Рәис улына, генераль директорның техник хезмәт күрсәтү һәм инжиниринг буенча урынбасары хезмәтенең технологик җиһазларга техник хезмәт күрсәтү һәм аларны төзекләндерү хезмәте технологик җайланмаларны төзекләндерү слесаре **Макаров** Юрий Николаевичка, генераль директорның техник хезмәт күрсәтү һәм инжиниринг буенча урынбасары хезмәтенең техник хезмәт күрсәтү идарәсе баш приборчысы бүлегенең (күкертле нефть продуктларын гидрирлау (гидродеароматизация) җайланмасын эшләтеп җибәрү буенча) контроль-үлчәү приборлары һәм автоматлар буенча әйдәүче инженеры **Маслов** Игорь Сергеевичка, генераль директорның техник хезмәт күрсәтү һәм сыйфат буенча урынбасары хезмәтенең автоматлаштыру, метрология һәм элемтә җитештерү системалары идарәсе технологик процессларга идарә итүнең автоматлаштырылган системалары бүлеге башлыгы – баш белгече **Мөслимов** Ринат Рифкать улына, генераль директорның техник хезмәт күрсәтү һәм инжиниринг буенча урынбасары хезмәте технологик җиһазларга техник хезмәт күрсәтү һәм аларны төзекләндерү хезмәтенең күкертле нефтьләрне кудырту, крекинглау һәм алардан нефть продуктлары алу цехы технологик җиһазларга техник хезмәт күрсәтү һәм аларны төзекләндерү участогының нефть продуктларын су белән чистарту (нафта) җайланмасын һәм висбрекинг технологик җайланмаларын төзекләндерү буенча слесаре (дежурные) **Тугеев** Эдуард Джоновичка, «ГАРО» авыл хуҗалыгы продуктлары белән тәэмин итү-сату кулланучылар кооперативы рәисе **Галимуллин** Фаил Равил улына, «Альтаир-1» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте генераль директоры **Миначев** Ринат Садртдин улына, шәхси эшкуар «Михалева Елена Ивановна» **Михалева** Елена Ивановнага, Россия Федерациясе Кулланучылар җәмгыятьләре үзәк берлегенең «Россия кооперация университеты» югары белем бирү автоном коммерциячел булмаган мәгариф оешмасы ректоры **Нәбиева** Алсу Рөстәм кызына, «ГАРО» авыл хуҗалыгы продуктлары белән тәэмин итү-сату кулланучылар кооперативының авыл хуҗалыгы продуктларын хәзерләүче **Нурмөхәммәтов** Илнур Нургали улына, «Түбән Кама җылылык-электр үзәге» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте технологик процессларга идарә итүнең автоматлаштырылган системалары цехы башлыгы **Аблатипов** Фәрхәд Фәрид улына, «Түбән Кама җылылык-электр үзәге» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте инвестицияләрне гамәлгә ашыру бүлеге башлыгы **Никифоров** Николай Романовичка, В.Д. Шашин исемендәге «Татнефть» гавами акционер җәмгыятенең Скважиналарны җир астында төзекләндерү идарәсе скважиналарны җир астында төзекләндерү Әлмәт цехы башлыгы **Аввакумов** Виталий Николаевичка, В.Д. Шашин исемендәге «Татнефть» гавами акционер җәмгыятенең Төзелеш проектларын гамәлгә ашыру идарәсе проектлаштыру хезмәте җитәкчесе **Исмәгыйлева** Ольга Сергеевнага, В.Д. Шашин исемендәге «Татнефть» гавами акционер җәмгыятенең Скважиналарны җир астында төзекләндерү идарәсе скважиналарны җир астында төзекләндерү Лениногорск цехының скважиналарны төзекләндерү (капиталь, җир астында) буенча мастеры **Сабирҗанов** Радик Зәет улына, «ТАНЕКО» акционер җәмгыяте генераль директорының техник ярдәм күрсәтү һәм сыйфат буенча урынбасары хезмәтенең комплекс үзәк лабораториясе сыйфатка контроль лабораториясе инженер-химигы **Габдерафикова** Наталья Николаевнага, «Түбән Кама йөк машиналары шиннары заводы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең вулканлаштыру цехы резин эшләнмәләр һәм аяк киемнәре җитештерү җайланмасын көйләүче **Калмыков** Сергей Сергеевичка, «ТАНЕКО» акционер җәмгыяте генераль директорының техник ярдәм күрсәтү һәм сыйфат буенча урынбасары хезмәтенең техник үсеш идарәсе перспективалы үсеш бүлеге башлыгы **Каюпов** Альберт Рамазан улына, «ТАНЕКО» акционер җәмгыяте генераль директорының техник ярдәм күрсәтү һәм сыйфат буенча урынбасары хезмәтенең техник үсеш идарәсе баш технологы – баш технологы бүлеге башлыгы **Смирнов** Дмитрий Ивановичка, «БИГЕШ АЭРОПОРТЫ» акционер җәмгыяте генераль директорының беренче урынбасары – производство буенча директоры **Захаров** Дмитрий Александровичка, «БИГЕШ» АЭРОПОРТЫ» акционер җәмгыятенең капиталь төзелеш буенча директоры – баш инженеры **Шәрифуллин** Альберт Камил улына, «Алойл» ябык акционер җәмгыяте баш технологы хезмәте әйдәүче инженеры **Михайлов** Андрей Борисовичка, «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының Н.К. Крупская исемендәге 38 номерлы катнаш төрдәге балалар бакчасы» муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе мөдире **Тяпкова** Нина Георгиевнага, В.Д. Шашин исемендәге «Татнефть» гавами акционер җәмгыятенең Социаль объектлар идарәсе нефть музее мөдире **Фатыйхова** Ирина Ильяс кызына, В.Д. Шашин исемендәге «Татнефть» гавами акционер җәмгыятенең **«Татнефть-Добыча» структур бүлекчәсе «Лениногорскнефть» нефть һәм газ чыгару идарәсе коллективына**, «Евростиль» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте хезмәткәрләре: электр һәм газ белән эретеп ябыштыручы **Әхмәтшин** Румил Фарус улына, төзү эшләре җитәкчесе **Җиһаншин** Айрат Миннәхмәт улына, төзелеш маляры **Миңнуллина** Елена Владимировнага, Сәнәгатьнең һәм төзелешнең нефть, газ тармаклары хезмәткәрләре гомумроссия һөнәр берлеге «Татнефть Профсоюз» төбәкара һөнәр берлеге оешмасы рәисе **Яруллин** Гомәр Кәрим улына **Татарстан Республикасы Рәисенең Рәхмәте** белдерелде.

Комплексны кадастр эшләре башкарганда җир кишәрлекләре чикләренең урнашу урынын килештерү мәсьәләсе буенча килештерү комиссиясе утырышын үткәрү турында хәбәрнамә

Түбәндәге территориядә: Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Чистай муниципаль районы, Булдырь авыл җирлеге, «Водник» бакчачылык ширкәтендә урнашкан күчемсез милек объектларына карата (кадастр кварталы номеры 16:42:200703) 30.06.2023 № 923000220/2-ОК дәүләт контракты нигезендә комплексны кадастр эшләре башкарыла.

Кызыксынулы барлык затларга территорияләрнең карта-планнары проектларын әзерләүнең тәмамлануы, алар белән түбәндәге адреслар буенча танышырга мөмкин булуы турында хәбәр итәбез: барып – килештерү комиссиясенең эш урыны адресы: Татарстан Республикасы, Чистай районы, Йолдыз бистәсе, Үзәк урам, 1а й. (телефон: +7(84342) 3-43-55, 4-64-79), яки

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының (https://mzio.tatarstan.ru);

Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы хакимиятенең (https:// https://chistopol.tatarstan.ru);

Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе (https://rosreestr.tatarstan.ru) «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтларында.

Җир кишәрлекләре чикләренең урнашу урынын килештерү мәсьәләсе буенча килештерү комиссиясе утырышы 2023 елның 28 сентябрендә (11 сәгать 00 минутта башлана) түбәндәге адрес буенча үткәрелә: Татарстан Республикасы, Чистай районы, Йолдыз бистәсе, Үзәк урам, 1а й.

Чикләрнең урнашу урынын килештерүдә катнашу өчен, үзең белән шәхесне раслаучы документ, шулай ук тиешле җир кишәрлегенә хокукларны раслаучы документлар алып килергә кирәк.

Территориянең карта-планы проектындагы җир кишәрлекләре чикләренең урнашу урынына карата нигезле каршы килүләрне килештерү комиссиясенә язмача 2023 елның 4 сентябреннән 2023 елның 28 сентябренә кадәр һәм 2023 елның 28 сентябреннән 2023 елның 3 ноябренә кадәр тапшырырга мөмкин.

Каршы килүләр «Дәүләт күчемсез милек кадастры турында» 24 июль, 2007 ел, № 221-ФЗ Федераль законның 42.10 статьясындагы 15 өлеше нигезендә рәсмиләштерелә. Бу җәһәттән тәфсилле мәгълүматлар сайтта (https://mzio.tatarstan.ru) урнаштырылган.

Мондый каршы килүләр булмаган очракта, җир кишәрлекләре чикләренең урнашу урыны килештерелгән булып санала.

Комплексны кадастр эшләре башкарганда җир кишәрлекләре чикләренең урнашу урынын килештерү мәсьәләсе буенча килештерү комиссиясе утырышын үткәрү турында хәбәрнамә

Түбәндәге территориядә: Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Биектау муниципаль районы, Усад авыл җирлеге, «Фотохимик» бакчачылык ширкәтендә урнашкан күчемсез милек объектларына карата (кадастр кварталы номеры 16:16:171501) 30.06.2023 № 923000220/2-ОК дәүләт контракты нигезендә комплексны кадастр эшләре башкарыла.

Кызыксынулы барлык затларга территорияләрнең карта-планнары проектларын әзерләүнең тәмамлануы, алар белән түбәндәге адреслар буенча танышырга мөмкин булуы турында хәбәр итәбез: барып – килештерү комиссиясенең эш урыны адресы: Татарстан Республикасы, Биектау районы, Тимофеевка авылы, Профсоюз урамы, 45 й. (телефон: +7(84365) 73-2-75), яки

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының (https://mzio.tatarstan.ru);

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы хакимиятенең (https:// vysokaya-gora.tatarstan.ru);

Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе (https://rosreestr.tatarstan.ru) «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтларында.

Җир кишәрлекләре чикләренең урнашу урынын килештерү мәсьәләсе буенча килештерү комиссиясе утырышы 2023 елның 29 сентябрендә (10 сәгать 00 минутта башлана) түбәндәге адрес буенча үткәрелә: Татарстан Республикасы, Биектау районы, Дачное бистәсе, Үзәк урам, 11 й.

Чикләрнең урнашу урынын килештерүдә катнашу өчен, үзең белән шәхесне раслаучы документ, шулай ук тиешле җир кишәрлегенә хокукларны раслаучы документлар алып килергә кирәк.

Территориянең карта-планы проектындагы җир кишәрлекләре чикләренең урнашу урынына карата нигезле каршы килүләрне килештерү комиссиясенә язмача 2023 елның 5 сентябреннән 2023 елның 29 сентябренә кадәр һәм 2023 елның 29 сентябреннән 2023 елның 4 ноябренә кадәр тапшырырга мөмкин.

Каршы килүләр «Дәүләт күчемсез милек кадастры турында» 24 июль, 2007 ел, № 221-ФЗ Федераль законның 42.10 статьясындагы 15 өлеше нигезендә рәсмиләштерелә. Бу җәһәттән тәфсилле мәгълүматлар сайтта (https://mzio.tatarstan.ru) урнаштырылган.

Мондый каршы килүләр булмаган очракта, җир кишәрлекләре чикләренең урнашу урыны килештерелгән булып санала.

Комплексны кадастр эшләре башкарганда җир кишәрлекләре чикләренең урнашу урынын килештерү мәсьәләсе буенча килештерү комиссиясе утырышын үткәрү турында хәбәрнамә

Түбәндәге территориядә: Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Чистай муниципаль районы, Булдырь авыл җирлеге, «Дружба» бакчачылык ширкәтендә урнашкан күчемсез милек объектларына карата (кадастр кварталы номеры 16:42:200305) 30.06.2023 № 923000220/2-ОК дәүләт контракты нигезендә комплексны кадастр эшләре башкарыла.

Кызыксынулы барлык затларга территорияләрнең карта-планнары проектларын әзерләүнең тәмамлануы, алар белән түбәндәге адреслар буенча танышырга мөмкин булуы турында хәбәр итәбез: барып – килештерү комиссиясенең эш урыны адресы: Татарстан Республикасы, Чистай районы, Йолдыз бистәсе, Үзәк урам, 1а й. (телефон: +7(84342) 3-43-55, 4-64-79, яки

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының (https://mzio.tatarstan.ru);

Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы хакимиятенең (https:// https://chistopol.tatarstan.ru);

Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе (https://rosreestr.tatarstan.ru.) «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтларында.

Җир кишәрлекләре чикләренең урнашу урынын килештерү мәсьәләсе буенча килештерү комиссиясе утырышы 2023 елның 28 сентябрендә (09 сәгать 00 минутта башлана) түбәндәге адрес буенча үткәрелә: Татарстан Республикасы, Чистай районы, Йолдыз бистәсе, Үзәк урам, 1а й.

Чикләрнең урнашу урынын килештерүдә катнашу өчен, үзең белән шәхесне раслаучы документ, шулай ук тиешле җир кишәрлегенә хокукларны раслаучы документлар алып килергә кирәк.

Территориянең карта-планы проектындагы җир кишәрлекләре чикләренең урнашу урынына карата нигезле каршы килүләрне килештерү комиссиясенә язмача 2023 елның 4 сентябреннән 2023 елның 28 сентябренә кадәр һәм 2023 елның 28 сентябреннән 2023 елның 3 ноябренә кадәр тапшырырга мөмкин.

Каршы килүләр «Дәүләт күчемсез милек кадастры турында» 24 июль, 2007 ел, № 221-ФЗ Федераль законның 42.10 статьясындагы 15 өлеше нигезендә рәсмиләштерелә. Бу җәһәттән тәфсилле мәгълүматлар сайтта (https://mzio.tatarstan.ru) урнаштырылган.

Мондый каршы килүләр булмаган очракта, җир кишәрлекләре чикләренең урнашу урыны килештерелгән булып санала.

Комплексны кадастр эшләре башкарганда җир кишәрлекләре чикләренең урнашу урынын килештерү мәсьәләсе буенча килештерү комиссиясе утырышын үткәрү турында хәбәрнамә

Түбәндәге территориядә: Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Чистай муниципаль районы, Булдырь авыл җирлеге, «Энергетик-2» бакчачылык ширкәтендә урнашкан күчемсез милек объектларына карата (кадастр кварталы номеры 16:42:200702) 30.06.2023 № 923000220/2-ОК дәүләт контракты нигезендә комплексны кадастр эшләре башкарыла.

Кызыксынулы барлык затларга территорияләрнең карта-планнары проектларын әзерләүнең тәмамлануы, алар белән түбәндәге адреслар буенча танышырга мөмкин булуы турында хәбәр итәбез: барып – килештерү комиссиясенең эш урыны адресы: Татарстан Республикасы, Чистай районы, Йолдыз бистәсе, Үзәк урам, 1а й. (телефон: +7(84342) 3-43-55, 4-64-79), яки

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының (https://mzio.tatarstan.ru);

Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы хакимиятенең (https:// https://chistopol.tatarstan.ru);

Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе (https://rosreestr.tatarstan.ru) «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтларында.

Җир кишәрлекләре чикләренең урнашу урынын килештерү мәсьәләсе буенча килештерү комиссиясе утырышы 2023 елның 28 сентябрендә (10 сәгать 00 минутта башлана) түбәндәге адрес буенча үткәрелә: Татарстан Республикасы, Чистай районы, Йолдыз бистәсе, Үзәк урам, 1а й.

Чикләрнең урнашу урынын килештерүдә катнашу өчен, үзең белән шәхесне раслаучы документ, шулай ук тиешле җир кишәрлегенә хокукларны раслаучы документлар алып килергә кирәк.

Территориянең карта-планы проектындагы җир кишәрлекләре чикләренең урнашу урынына карата нигезле каршы килүләрне килештерү комиссиясенә язмача 2023 елның 4 сентябреннән 2023 елның 28 сентябренә кадәр һәм 2023 елның 28 сентябреннән 2023 елның 3 ноябренә кадәр тапшырырга мөмкин.

Каршы килүләр «Дәүләт күчемсез милек кадастры турында» 24 июль, 2007 ел, № 221-ФЗ Федераль законның 42.10 статьясындагы 15 өлеше нигезендә рәсмиләштерелә. Бу җәһәттән тәфсилле мәгълүматлар сайтта (https://mzio.tatarstan.ru) урнаштырылган.

Мондый каршы килүләр булмаган очракта, җир кишәрлекләре чикләренең урнашу урыны килештерелгән булып санала.

Комплексны кадастр эшләре башкарганда җир кишәрлекләре чикләренең урнашу урынын килештерү мәсьәләсе буенча килештерү комиссиясе утырышын үткәрү турында хәбәрнамә

Түбәндәге территориядә: Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Совет районы, «Татпотребсоюз» бакчачылык ширкәтендә урнашкан күчемсез милек объектларына карата (кадастр кварталы номеры 16:50:140425) 02.05.2023 № №923000089-ОК дәүләт контракты нигезендә комплексны кадастр эшләре башкарыла.

Кызыксынулы барлык затларга территорияләрнең карта-планнары проектларын әзерләүнең тәмамлануы, алар белән түбәндәге адреслар буенча танышырга мөмкин булуы турында хәбәр итәбез: барып – килештерү комиссиясенең эш урыны адресы: Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Совет районы, Шуртыгин урамы, 1 й. (телефон: +7 843 223-20-00) яки

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының (https://mzio.tatarstan.ru);

Татарстан Республикасы Казан шәһәре муниципаль берәмлеге башкарма комитетының Совет районы хакимияте (https://kzn.ru/meriya/administratsii-rayonov/sovetskiy);

Казан шәһәре муниципаль берәмлеге башкарма комитетының җир һәм милек мөнәсәбәтләре комитеты (https://rosreestr.tatarstan.ru);

Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе (https://rosreestr.tatarstan.ru) «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтларында.

Җир кишәрлекләре чикләренең урнашу урынын килештерү мәсьәләсе буенча килештерү комиссиясе утырышы 2023 елның 2 октябрендә (10 сәгать 00 минутта башлана) түбәндәге адрес буенча үткәрелә: Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Совет районы, Шуртыгин урамы,1 й.

Чикләрнең урнашу урынын килештерүдә катнашу өчен, үзең белән шәхесне раслаучы документ, шулай ук тиешле җир кишәрлегенә хокукларны раслаучы документлар алып килергә кирәк.

Территориянең карта-планы проектындагы җир кишәрлекләре чикләренең урнашу урынына карата нигезле каршы килүләрне килештерү комиссиясенә язмача 2023 елның 8 сентябреннән 2023 елның 2 октябренә кадәр һәм 2023 елның 2 октябреннән 2023 елның 7 ноябренә кадәр тапшырырга мөмкин.

Каршы килүләр «Дәүләт күчемсез милек кадастры турында» 24 июль, 2007 ел, № 221-ФЗ Федераль законның 42.10 статьясындагы 15 өлеше нигезендә рәсмиләштерелә. Бу җәһәттән тәфсилле мәгълүматлар сайтта (https://mzio.tatarstan.ru) урнаштырылган.

Мондый каршы килүләр булмаган очракта, җир кишәрлекләре чикләренең урнашу урыны килештерелгән булып санала.

Комплексны кадастр эшләре башкарганда җир кишәрлекләре чикләренең урнашу урынын килештерү мәсьәләсе буенча килештерү комиссиясе утырышын үткәрү турында хәбәрнамә

Түбәндәге территориядә: Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Совет районы, «Мечта» бакчачылык ширкәтендә урнашкан күчемсез милек объектларына карата (кадастр кварталы номеры 16:50:140419) 02.05.2023 № №923000089-ОК дәүләт контракты нигезендә комплексны кадастр эшләре башкарыла.

Кызыксынулы барлык затларга территорияләрнең карта-планнары проектларын әзерләүнең тәмамлануы, алар белән түбәндәге адреслар буенча танышырга мөмкин булуы турында хәбәр итәбез: барып – килештерү комиссиясенең эш урыны адресы: Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Совет районы, Шуртыгин урамы, 1 й. (телефон: +7 843 223-20-00), яки

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының (https://mzio.tatarstan.ru);

Татарстан Республикасы Казан шәһәре муниципаль берәмлеге башкарма комитетының Совет районы хакимияте (https://kzn.ru/meriya/administratsii-rayonov/sovetskiy);

Казан шәһәре муниципаль берәмлеге башкарма комитетының җир һәм милек мөнәсәбәтләре комитеты (https://rosreestr.tatarstan.ru);

Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе (https://rosreestr.tatarstan.ru) «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтларында.

Җир кишәрлекләре чикләренең урнашу урынын килештерү мәсьәләсе буенча килештерү комиссиясе утырышы 2023 елның 2 октябрендә (11 сәгать 00 минутта башлана) түбәндәге адрес буенча үткәрелә: Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Совет районы, Шуртыгин урамы, 1 й.

Чикләрнең урнашу урынын килештерүдә катнашу өчен, үзең белән шәхесне раслаучы документ, шулай ук тиешле җир кишәрлегенә хокукларны раслаучы документлар алып килергә кирәк.

Территориянең карта-планы проектындагы җир кишәрлекләре чикләренең урнашу урынына карата нигезле каршы килүләрне килештерү комиссиясенә язмача 2023 елның 8 сентябреннән 2023 елның 2 октябренә кадәр һәм 2023 елның 2 октябреннән 2023 елның 7 ноябренә кадәр тапшырырга мөмкин.

Каршы килүләр «Дәүләт күчемсез милек кадастры турында» 24 июль, 2007 ел, № 221-ФЗ Федераль законның 42.10 статьясындагы 15 өлеше нигезендә рәсмиләштерелә. Бу җәһәттән тәфсилле мәгълүматлар сайтта (https://mzio.tatarstan.ru) урнаштырылган.

Мондый каршы килүләр булмаган очракта, җир кишәрлекләре чикләренең урнашу урыны килештерелгән булып санала.

ХА-ХА-ХАНӘ

Шушы урында көләсе

Мач әйткән!

Коко ШАНЕЛЬ, модельер:

– Әгәр сез канатсыз тугансыз икән, һич югы аларның үсүенә комачауламагыз.

Әз-мәз мәзәк

Берзаман синең телефоныңа бик матур код киләчәк. Әмма син бу шатлыкны берәүгә дә сөйли алмаячаксың. Чөнки банк бу кодны берәүгә дә әйтергә кушмый.

* * *

– Ничек шулай тыныч була аласың?
– Юләрләр белән бәхәсләшмим чөнки.
– Нәрсә сөйлисең син, алар белән бәхәсләшми мөмкинмени соң инде?
– Ярар, синеңчә булсын.

* * *

– Ни өчен кызларның чәчләре коела?
– Чөнки бу кадәр косметика кулланудан чәчләр көчле генә түгел, ә мөстәкыйль дә була башлый һәм хуҗасыннан кача.

* * *

– Әбекәй, ни өчен бүген гөмбәләреңне кыйммәтрәк сатасың?
– Доллар үсте бит, улым.
– Америка урманнарыннан мәллә гөмбәң?

* * *

Эскалатордан йөгерүче кешеләрдән сорыйсы килә: сез экономияләнгән вакытыгызны нишләтәсез ул?

БӘХЕТ АКЧАДА ТҮГЕЛ

vk.com

«Форбс» журналы исемлеге бар. Коммуналь түләүләр өчен бурычлылар исемлеге бар. Әгәр син берсенә дә кермисең икән, димәк, син – «урта хәлле» класс.

Белгечләр мондый киңәш бирә: 60 сумнан алган долларларыгызны гына сумга алыштырыгыз, 80 сумга алынганнары торып торсын.

Саран ике түләр, ди. Саранга эшкә урнашыгыз.

«Мин сине яратам» дигән сүзне ишетү рәхәт. Әмма банкомат акча биргәндәге «трррррр...» дигән тавыш колакка барыбер рәхәтрәк.

Финанс хәлем: каһвәне өйдә генә эчәм.

Сәхифәне Данил СӘФӘРОВ әзерләде

Юмореска

КАРБЫЗ КЫЙССАСЫ

Карбыз – җәйнең күрке. Ни карга, ни бозга бер катнашы булмаса да, татар аны никтер «карбыз» дип атаган. Җиләккә охшамаса да, биология классификациясе буенча җиләк санала ул. Бу татлы ризык җәй башыннан ук сатыла башлый. Әмма безнең халык юләр түгел, майдан ук алырга ашыкмый аны. Беренчедән, иртә карбызлар нитратлы була дип сөйлиләр. Гади кеше нитратның нәрсә икәнен аңламаса да, куркыныч яңгырый бит. Күрше сөйләве буенча, нитратны эчкә шприц белән кертәләр икән. Шуңа күрә карбызны сатып алгач, иң элек энә эзе юкмы дип тикшереп чыгам. Мине алдамассың! Икенчедән, җәй ахырында карбыз арзанрак була. Шуны белә торып, аны җәй башында ничек аласың инде?

Август аенда карбыз – бик шәп күчтәнәч. Үзе зур, үзе арзан, үзен бөтен кеше ярата. Тик шунысы бар: башка кунаклар да күчтәнәчкә, «үзе зур, үзе арзан, үзен бөтен кеше ярата» дип, карбыз күтәреп килергә мөмкин. Пикникка чыксаң, әлеге татлы җиләк гел игътибар үзәгендә. Шашлык ясауны санамаганда, иң җаваплы эш ул – карбыз кисү. «Бир әле монда, үзем кисәм», «карбыз кисү хатын-кыз эше түгел» дигән сүзләр еш ишетелә андый чакта. Көнкүрештә дә карбызның файдасы бик зур. Менә сезгә лайфхак: иртән йоклап калырмын дип курыксагыз, кичтән карбыз ашап ятыгыз.

Карбызның ничек үскәнен бер дә күргәнем юк. Кырда үсә, диләр. Аны караклардан саклау бик авырдыр. Ишеткәнем бар, бер хуҗа, аптырагач, «бер карбызның эченә агу салынган» дип язып куйган. Икенче көнне килеп караса, шул язуга берсе болай дип өстәгән ди: «хәзер инде ике карбызның эченә агу салынган».

Мичуриннар карбыз белән нинди генә эксперимент ясап карамады. Төшсез карбыз, сары карбыз, ташырга уңайлы дип японнар хәтта шакмаклы карбыз үстереп карадылар. Мичурин үзе дә шушы җиләктән үлгән, дип сөйлиләр. Тупыл агачына укроп җыярга менгәндә башына карбыз төшкән, имеш.

Бер көнне таныш үзбәк сатучысына кердем. Карбызны суккалап-каккалап сайлап бирде. Шулхәтле күңелем булды. Таныш кеше таныш кеше инде. Шулай шатланып кайтып барганда башыма көфер фикер килде. Бер уйласаң, миңа хәтле суккалаудан калган карбызлар бит инде бу. Миннән соң килгән алучыларга да шуларны ук суккалап сатып бетерәчәк, үзендә калдырмаячак. Алайса, суккалап сайлауның мәгънәсе нидә? Вәт сиңа таныш!

Карбыз турында язып, ничәмә-ничә журналист гонорар эшләде. Менә бу язма да шуның бер мисалы... дип әйтә яздым. Ничек сайларга? Сугыпмы-сыгыпмы? Сары табы бармы? Койрыгы кипкәнме? Җәй көннәрендә матбугатта карбыз турында даими рубрика ачарга була хәтта. Кыскасы, бу җиләк турында күп сөйләргә һәм язарга була. Киттем әле мин, суыткычта ярты карбызым бар иде, сезнең белән вакыт үткәргән арада өйдәгеләр уртасын ашап бетермәсеннәр тагын.

vk.com

Пешмәгән

Роберт МИҢНУЛЛИН

Сатып алдым мин карбыз.
Тәмле микән? Карарбыз!
Турадым өйдә ваклап.
Ә эче... эче ап-ак.
Тукта, тукта, туктагыз –
Пешмәгән бит бу карбыз...
Ә бит күпме сайладым?!

Бик-бик күпне сайладым.
Чирткәләгән дә идем,
Төрткәләгән дә идем,
Каккалаган да идем,
Суккалаган да идем...
Менә бит нишләгәнмен –
Үзем дә пешмәгәнмен!

КӨФЕР УЙЛАР

- Чәчтарашханәдә иң авыры – 20 минут үзеңнең йөзеңә карап утыру.
- Урта яшь кризисыннан самокат белән генә кача алмассың!
- Башта син зачеткаңа эшлисең, аннары – икенче курста куылган дустыңа.
- Төрмәдә утыруның кечкенә генә плюслары да бар. Әйтик, ял көне җиткәч, дачага барасы юк.
- Күсе өчен иң үкенечлесе – соңыннан корабның батмый калуы.
- Стоматолог кабинетында иң куркынычы – докторның синең авызны фотога төшереп, социаль челтәргә элеп куюы.
- Тузганактан кайнатма ясарга өйрәнгәнне ни өчен ташкабактан компот кайната белмибез?
- Иң сәер күренеш – әти-әнинең үз баласын «тәрбиясез» дип орышуы.
- Каравылчы, гардероб хезмәткәре, консьерж... Бу кешеләргә акчаны без башка кешеләргә ышанмаганга түлибез.
- Тәмле токмач ашы рецептында иң мөһим компонент – тамагы ачкан ирең.
- Хатынымның миңа ни өчен «син – минем җанымның яртысы» дип эндәшүен аңладым. Ул – 120 кило, ә мин 60 кына.
- Ракетаны космоска җибәрмәсәләр, ул озаграк сакланыр иде.
- Өйдә озаграк яткан саен, өе булмаган кешегә күбрәк охшый башлыйсың.
- Гадәттә, түләүле кинолог белән шөгыльләнгәндә мин кинолог алдында да, этем алдында да оятка калам.

vk.com

- Стакан тулы булса, оптимист та, пессимист та шат.
- Эшләмәгән эшләрем белән мин бик канәгать.

НЕРВЫГЫЗНЫ САКЛАГЫЗ

Медицинада «Плацебо эффекты» дигән күренеш бар. Сиңа дәвалау өчен бәяне әйткәч, шундук бөтен чирләрең кача һәм үзеңне яхшы хис итә башлыйсың.


vk.com

* * *

Минем психиатр болай ди:
– Син берүзең булганда начар түгел әле бу. Менә син икәү булганда, монысы начар.

* * *

– Ой, син соңгы арада матурланып киттең, яшәреп киттең. Кемеңдер бар, ахры?
– Әйе. Яңа психологым.

* * *

– Матурым, кичкә берни планлаштырма. Мин өстәлгә заказ бирдем.
– Нинди өстәлгә?
– Психолог бүлмәсендәге.

* * *

– Доктор, минем башымда гел музыка уйный.
– Шуннан?
– Ничек инде шуннан? Мин ул җырны яратмыйм.

* * *

Психологка инде дүртенче елымны йөрим. Нәтиҗәләр әйтеп бетергесез. Дүрт ел эчендә ул фатир алды, машинасын яңартты, дүрт тапкыр диңгезгә барды.

Өйләнү – түгел сөйләнү

– Син өйләнгәнме?
– Бу аккаунтта – юк.

❤❤❤

Ошаткан кызларыгызны якыннан белергә тырышмагыз, әгәр алга таба да аларны ошатырга телисез икән.

❤❤❤

– Ир кешедә иң мөһиме – юмор хисе. Шуңа күрә мин олигархларның юмор хисле булганнарына кызыгам.

❤❤❤

Балачакта болай иде. Малай минем белән уйнарга теләмәсә, мин башка малай таба идем. Ул чактан берни үзгәрмәде.

❤❤❤

Аерылышуда һәрвакыт ике кеше гаепле: мужик һәм аның сөяркәсе.

❤❤❤

– Ә ни өчен син һаман өйләнмәгән?
– Чөнки муенымда мине саклый торган бөтием бар.

❤❤❤

– Мине бу дөньяда берни белән шаккатырып булмый, минем туемнан башка.

❤❤❤

– Мин сине шундый сагындым! Эш көне кайчан бетәр дә, өйгә кайтып, синең куеныңа кайчан керермен дип, минутларны саныйм.
– Кайтканда ипи ал.

❤❤❤

– Лилия, минем сиңа әйтәсе сүзем бар.
– Куркытма, әйт.
– Мин өйләнгән.
– Уф! «Мерседес» минеке түгел дип әйтәсең дип торам.

vk.com

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ,
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ АППАРАТЫ
Газета Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә 2023 елның 23 августында теркәлгән.
Теркәү таныклыгының номеры – ПИ № ТУ16-01758.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Тираж – 5159 данә
Гомуми тираж – 14047 данә

Газетага сертификат бирелде Заказ 323

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040
Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.
Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.
Ваклап сату бәясе килешү буенча.
Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+